2001 елның августыннан чыга

# Мәйдан

№4 (233)

**АПРЕЛЬ /2021**

Гамәлгә куючы:
«Татмедиа» акционерлык җәмгыяте
(420097, Казан, Академиклар урамы, 2)

Баш редактор Рөстәм Госман улы ГАЛИУЛЛИН

РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:

**Әлфия ӘДИЯТОВА** (Казан)
**Фирдүсә ӘЮПОВА** (Чаллы)
**Дилбәр БУЛАТОВА** (Уфа)
**Разил ВӘЛИЕВ** (Казан)
**Фәридә ГАБИДУЛЛИНА** (Алабуга)
**Рафаил ГАЗИЗОВ** (Мамадыш)
**Фоат ГАЛИМУЛЛИН** (Казан)
**Рөстәм ГАНИЕВ** (Түбән Кама)
**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА** (Казан)
**Илдус ЗАҺИДУЛЛИН** (Казан)
**Наил МӘҺДИЕВ** (Чаллы)
**Илдар МИРГАЛИМОВ** (Казан)
**Рүзәл МӨХӘММӘТШИН** (Казан)
**Фоат САДРИЕВ** (Мөслим)
**Ркаил** + (Казан)
**Факил САФИН** (Чаллы), редакция советы рәисе
**Равил ФӘЙЗУЛЛИН** (Казан)
**Энгель ФӘТТАХОВ** (Актаныш)
**Рамил ХӘЛИМОВ** (Чаллы)
**Рәфкать ШАҺИЕВ** (Әлмәт)
**Әнвәр ШӘРИПОВ** (Чаллы)
**Рафаэль ЮНЫСОВ** (Чаллы)

РЕДАКЦИЯ КОЛЛЕКТИВЫ:

иҗат төркеме:

**Факил САФИН** (баш редактор урынбасары)
**Гөлшат ИЛАЛЕТДИНОВА** (җаваплы секретарь)
**Гөлнар КАРАЕВА** (сайт редакторы)
**Лилия ГЫЙБАДУЛЛИНА** (шигърият бүлеге)
**Светлана ФӘИЗОВА** (проза бүлеге)
**Сәмәрә ХӘЙРУЛЛИНА** (гомуми бүлек редакторы)

гамәли хезмәткәрләр:

**Резеда ГАТИНА** (баш бухгалтер)
**Индира ВӘЛИЕВА** (компьютерда биткә салу операторы)

Идел буе регионында Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәте идарәсендә ПИ № ФС77-76913 саны белән 2019 елның 1 октябрендә теркәлгән. Журналның индексы – П2356.
Редакция һәм нәшрият адресы: 423827, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Яшь ленинчылар бульвары, 9 нчы йорт (27/19), «Мәйдан». Телефоннар: (8552) 59-75-84, 59-65-84.

E-mail: **maydan06@mail.ru**, сайт адресы: **maydan.tatar**

Җыярга тапшырылды: 26.02.21. Басарга кул куелды: 30.03.21. Компьютерда җыелды. Катнаш гарнитура. Офсет ысулы белән басылды. Күләме – 10,0 басма табак.
Форматы: 70x100/16. Тиражы – 1569 данә. Заказ – Е-955.
Ярты елга язылу бәясе – 507 сум.

Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый. Редакция фикеренә тәңгәл килмәгән язмалар да басыла. Күчереп басканда «Мәйдан»нан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри. Авторларның язмаларында табылган хаталар һәм кимчелекләр өчен редакция җавап бирми.

6+

«Татмедиа» акционерлык җәмгыяте филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2.

© «Мәйдан», 2020.

| | | |
|---|---|---|
| **Татар шигыре** | **3** | Рәшит ӘХМӘТҖАНОВ. **Бергәләп җырлыйк** |
| | **4** | Әхмәт РӘШИТ. **Бер анадан тумасак та...** |
| **Чәчмә әсәр** | **5** | Хәбир ИБРАҺИМОВ. **Кызыл утрау** |
| **Шигъри гөләндәм** | **35** | Габдулла ТУКАЙ. **Дөньяны пакьли алмадым...** |
| **Чәчмә әсәр** | **39** | Әлфия СИТДЫЙКОВА. **Диңгез суы тозлы ул** |
| **Шигъри гөләндәм** | **85** | Факил САФИН. **Төсләр, төсмерләр** |
| **Тарих** | **89** | Булат ХӘМИДУЛЛИН**. Алтын Урда һәм аның тарихи мирасы** |
| **Шигъри гөләндәм** | **102** | Рәшит Гәрәй. **Җырларым сиңа булсын...** |
| **Тормыш һәм гамь** | **106** | Айдар ХӘЛИМ. **Дөньяда бердәнбер** |
| **Чаллы хикәяләре антологиясе** | **112** | Рахмай ХИСМӘТУЛЛИН. **Чылбырлар** |
| **Илһам канатларында** | **123** | Гөлчәчәк ХАҖИЕВА. |
| | **125** | Динара ХӨСНЕТДИНОВА. **Әйтер сүзем** |
| **Татарстанда Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы** | **126** | Гүзәл ТӨХВӘТОВА. **Габдулла Тукай музейлары** |
| **Истәлекләр** | **134** | Мәҗит ГАФУРИ. **Габдулла Тукай Уфада** |
| | **137** | Исмәгыйль РӘМИЕВ. **Хәтеремдә саклanганнардан** |
| **Шаян сәхифә** | **138** | Габдулла ТУКАЙ. **Килештерүче** |
| | **140** | **Мәкаләи махсуса** |
| | **142** | **Үткен пәке** |
| **Әдәби-иҗтимагый тормыш** | **143** | |
| **«Мәйданчык» кушымтасы** | **145** | Лилия Гыйбадуллина. **Куян күчтәнәче** |

Тышлыкның 1 нче битендә – Габдулла Тукай әдәби музее урнашкан тарихи бина – сәүдәгәр Ибраһим Апаков йорты. Казан. *(Гүзәл Төхвәтова фотосы)*



Булат ХӘМИДУЛЛИН

# Алтын Урда һәм аның тарихи мирасы

Булат Хәмидуллин кыпчак балбалы янында

2020 елда Татарстан күренекле вакыйганы – Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүнең 100 еллыгын, татар халкы дәүләтчелеге торгызылуның 100 еллыгын билгеләп узды.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасы Россия Федерациясенең тотрыклы үсеш кичерүче субъектлары исәбенә керә, ул – гаять куәтле социаль-икътисади, мәдәни, белем бирү һәм фәнни потенциалга ия төбәк. Республика актив рәвештә халыкара мөнәсәбәтләрдә катнаша, анда чит илләрдәге абруйлы оешмалар белән берлектә зур спорт чаралары, мәдәни, фәнни һәм икътисади чаралар уздырыла. Татарстан халыкларының III корылтаендагы чыгышында Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханов: «Совет дәвереннән соңгы чорда Татарстан үрнәге иң уңышлы үсеш модельләренең берсе булды. Республиканың бүгенге көнгә ирешкән казанышлары – төрле милләт вәкилләренең күп кенә буыннарының тырыш хезмәте нәтиҗәсе ул. Татарстан уңышлылыгының турыдан-туры уртак Ватаныбыз – Россиянең дә уңышлылыгы икәнлеген аңлауда без бердәм фикердә», – дип билгеләп үтте. Чыннан да, 1920 елдан алып, 100 ел эчендә Татарстан Рос-



Алтын Урда шәһәрләре. Каталон атласы, XIV гасыр.

сия империясенең гадәти аграр губернасы халәтеннән күтәрелеп, Россия Федерациясенең көчле икътисадлы, әйдәп баручы субъектларының берсе булган республикага кадәрге озын, әйтергә кирәк, сикәлтәле юл узды. 100 ел эчендә татар халкы да үз үсешендә зур сикереш ясады.

Россия империясендә яшәгән татар халкының 1905–1907 еллардагы демократик революциядән соң башланган һәм 1917 елгы Февраль революциясеннән соң тәмам оешып җиткән куәтле этносәяси хәрәкәте совет җитәкчелеген татар милли дәүләтчелеге проблемасына яңача карарга һәм автономияле Татарстан республикасын төзү буенча конкрет адымнарга барырга мәҗбүр итә. Республиканың хокуклары шактый ук чикләнсә дә, XVI гасырның икенче яртысында үзенең милли дәүләтчелегеннән мәхрүм ителгән татар халкы өчен әлеге вакыйга шул чорга карата ифрат зур казаныш була. Еракта калган легендар заманнар, үзенең бай тарихи үткәне хакындагы хатирәләрне татар халкы гасырлар дәвамында хәтерендә саклап килә.

Хәзерге Татарстан территориясендә дәүләтчелек тарихының тамырлары тирән, алар урта гасырлардагы Гуннар империясе, Төрки һәм Хәзәр каганлыклары кебек дәүләтләргә барып тоташа. II–VII гасырларда, «Халыкларның бөек күчеше» дип аталган чорда, Урта Идел буйларына актив рәвештә төрки-угор кабиләләре үтеп керә. VI–VIII гасырларда төбәктә шактый ишәйгән төрки телле халык-кабиләләрнең мәдәнияте Төрки һәм Хәзәр каганлыклары, Кара диңгез буендагы Бөек Болгар мәдәниятенә якын була. VII гасырның 70 нче елларында Бөек Болгар хәзәрләр тарафыннан яулана һәм болгарларның (Бөек Болгарның дәүләт төзегән халкының) бер өлеше Кара диңгез буйларының төньяк, Каспий буеның көнбатыш һәм Төньяк Кавказ төбәкләреннән Урта Идел буйларына күченеп килә.

X гасырда хәзерге Татарстан Республикасы территориясендә, атаклы Балтыйк-Идел сәүдә юлының нәкъ үзәгендә, болгарлар Урта Идел буенда һәм Урал янында беренче дәүләт – Идел-Чулман Болгарстанын төзиләр; аның составына күп кенә җирле төрки, фин-угор һәм, ихтимал, хәтта балт-славян кабиләләре дә керә, дәүләт башта (ул буйсынган Хәзәр ка-

ганлыгы X гасырның соңгы утызъеллыгында җимерелгәнчегә кадәр) ике биләмәдән – Болгар һәм Суар бәкләкләреннән тора.

Археология ядкарьләренең урыннары Идел-Чулман Болгарстанының территориясен гомуми яссылыкта күзалларга мөмкинлек бирә – болгар дәверенең төп истәлекләре Татарстан Республикасы һәм Чуваш Республикасы, Ульяновск, Самара һәм Пенза өлкәләре территорияләрендә урнашкан. XII гасыр ахырына болгар идарәчеләре үзләренең йогынтыларын Каманың югары агымы (хәзерге Пермь крае) һәм Иделнең түбән агымы (хәзерге Әстерхан өлкәсе) буйларына җәелдерәләр. Болгар дәүләтендә IX–XII гасырларда нигезләнгән кирмәннәр, кальгалар, шәһәрләр һәм авыллар күп була (1200 дән артык). Болгар, Суар, Биләр, Алабуга, Бряхимов (Ибраһим), Җүкәтау, Ашлы, «Муром шәһәрчеге», «Хулаш шәһәрчеге», «Юл шәһәрчеге» һ.б. мөһим хәрби-сәяси һәм мәдәни-икътисади үзәкләргә әвереләләр. Шул замандагы борынгы рус һәм Көнбатыш Европа шәһәрләре белән чагыштырганда, күләмнәре һәм халкы буенча, болгар шәһәрләре зуррак булганнар. Мәсәлән, Биләр (рус елъязмаларындагы «Бөек шәһәр», «Олуг кала») 800 гектардан артык мәйдан биләгән, анда 50 меңнән артык кеше яшәгән. Идел-Чулман Болгарстаны тормышында Дәште-Кыпчак һәм Төньяк Кавказ, Габбасыйлар хәлифәлеге һәм Хәрәзем, төньяк һәм көньяк рус кенәзлекләре, Византия, Балтыйк буе һәм Скандинавия, Һиндстан, Әфганстан һәм Кытай белән сәяси, сәүдә-икътисади һәм мәдәни багланышлар үстерү зур роль уйный.

Дәүләттә ислам дине хакимлек итә, ул Идел-Урал төбәгенә IX гасырның икенче яртысында үтеп керә башлый һәм 922 елда Болгарстанның рәсми дәүләт диненә әверелә. Шул ук елда Идел Болгарстанында Багдад хәлифәсе әл-Моктадир илчелеге булып китә, бу вакыйга исламның позицияләре ныгуга һәм Болгарстанның дипломатия җәһәтендә дөньяда мөселман иле булып танылуына зур йогынты ясый. X гасыр ахырыннан асылда илнең барлык халкы мөселманлыкта була. X–XIII гасырларда Урта Идел буе һәм Урал яны чикләрендә болгар, бәрәнҗәр, барсил (берсула), биләр, суар (суаз, савир), әсәгаль кабиләләреннән, бортас, мадьяр, кыпчак һәм угыз-бәҗәнәк кабиләләренең аерым төркемнәреннән бердәм болгар этносы (бердәм тел, рухи һәм матди мәдәният) формалаша, Болгарстан игенчелек, терлекчелек, шәһәр төзелеше, һөнәрчелек һәм сәүдә югары үсеш алган илгә әверелә – әлеге факт Көнчыгыш Европада үзенчәлекле болгар цивилизациясенең хөкем сөрүе хакында сүз йөртергә нигез бирә. Бу исә дәүләттә сәнгатьнең төрле төрләре һәм әдәбият, фән, монументаль архитектура үсеше белән дә расланa. Тармакланган һәм күп баскычлы мәгариф системасы нигезендә Болгарстан халкы (ир-атлар һәм хатын-кызлар, мәсәлән, хатын-кызларның Туйбикә һәм Рабига мәдрәсәләрендә) дин һәм дөньяви фәннәр нигезләрен өйрәнә, тарихта исемнәре танылган болгар дин галимнәре, философлар, язучылар, тарихчылар һәм географлар, башка фәннәр вәкилләре үсеп чыга (мәсәлән, шагыйрь Кол Гали, тарихчы Якуб ибне Ногман, табиб Таҗетдин ибне Юныс әл-Болгари, фи-



Панно кисәкчеге. Кашин, полихром мозаика. Улус Джучи. XIV гасыр. Болгар.



Фантастик хайваннар сурәтләре белән бизәлгән көзге. Бронза. Улус Джучи. XIII–XIV гасыр башы. Болгар.

лософлар һәм язучылар Сөләйман ибне Давыт әс-Саксини әс-Суари, Әбелгалә Хәмид әл-Болгари, Борһанетдин әл-Болгари, Газнәвиләр дәүләтенең бөек солтаны Ямин әд-Дәүлә Мәхмүд Газнәвинең остазы һәм вәзире Хуҗа Әхмәд әл-Болгари).

Шулай итеп, XIII гасырга аяк басканда Идел-Чулман Болгарстаны бөтендөнья тарихында чын мәгънәсендә үзенә бер төрле һәм күренекле чынбарлыкка әверелә. 1230 еллар уртасында «Бөек Венгрия»не эзләп, көнчыгыш тарафка ике мәртәбә сәфәр кылган венгр монахы Юшан үзенең «Татарларның тормышы, дине һәм килеп чыгышы хакында хат» дип аталган әсәрендә: «Идел Болгарстаны – бай шәһәрләре булган бөек һәм куәтле патшалык», – дип яза. Әмма 1236–1237 еллардагы монголлар явы нәтиҗәсендә аңарчы берничә мөстәкыйль болгар әмирлегеннән гыйбарәт Болгарстан яшәүдән туктый һәм аның территориясе тулысынча XIII гасырның икенче яртысында Җүчи Олысы (Алтын Урда) составына керә. Соңрак Идел-Чулман Болгарстаны халкы урта гасырлар татар этносының мөһим компонентларының берсенә әверелә, ә илнең мәдәнияте татар тарихи-мәдәни мирасының әһәмиятле состав өлешен тәшкил итә.

Алтын Урда чорында Чыңгызый-Җүчиләрнең әлеге гаять зур империясендә төрки телле халыкларның сәяси, икътисади һәм этномәдәни туплануы җәһәтендә һәм урта гасырлар татар этносы формалашуында төп процесслар бара. Бүгенге көндә фәнни даирәгә Алтын Урданың 150 ләп шәһәре мәгълүм, бу факт үзе генә дә бөтенлекле Алтын Урда цивилизациясе хакында сүз йөртергә нигез бирә. Илнең иң эре шәһәрләре исәбенә Болгар (хәзерге Татарстан), Сарай әл-Мәхрусә һәм Хаҗитархан (Әстерхан өлкәсе), Сарай әл-Җәдид һәм Билҗәмин (Волгоград өлкәсе), Мухша/Наручат (Пенза өлкәсе), Үкәк (Саратов өлкәсе), Азак (Ростов өлкәсе), Маҗар (Ставрополь крае), Дәрбәнд (Дагестан), Кырык Ир һәм Кырым/Солхат (Кырым), Сарайчык һәм Сыгнак (Казахстан), Үргәнеч (Үзбәкстан), Аккирмән (Украина) һ.б. калалар кергән. Урта Идел буендагы Болгар, Җүкәтау, Иске Казан, Казан, Кашан, Кирмәнчек һ.б. Алтын Урда Болгар олысының административ



*«Шах-наме» Персид кулъязмасыннан миниатюра. 1330 еллар. Смитсен институты. Вашингтон*



*Коръән тышы. Алтын. Улуч Джучи. XIV гасырның беренче яртысы. Дәүләт эрмитажы*

хакимият, һөнәрчелек, сәүдә, мәдәни һәм дини тормыш үзәкләре булганнар. Тарихи чыганакларда Урта Идел буенда XV гасырның икенче утызъеллыгына кадәр үк, ягъни Казан ханлыгы оешканчы, үзәге Казанда урнашкан ниндидер дәүләти берләшмә булуы тәгаен күрсәтелә. Мәсәлән, XIII гасыр уртасында ук Бату хан улы Сартак тарафыннан «Казан Урдасы» оештырылуы хакында хәбәр бар. XIV гасырда, Болгар, Җүкәтау һәм Кирмәнчек шәһәрләре белән бергә, Казан җирле бәклекләрнең берсенең сәяси үзәге сыйфатында искә алына. Бу исә XIV гасырда Казанның Сарайдан, әмма әлегә бердәм Алтын Урда кысаларында, суверенлыгы үсүен күрсәтә.

Җүчи Олысының таркалуы Алтын Урда традицияләренең дәвамчылары булган һәм шактый ук бөтенлекле урта гасырлар конфедерациясен тәшкил иткән яңа дәүләтләр «йолдызлыгы» хасил булуга китерә.

1438 яисә 1445 елда башкаласы Казан булган, Идел Болгарстанының һәм Алтын Урданың этномәдәни һәм социаль-икътисади традицияләрен мирас итеп алган Казан ханлыгы оеша. Дәүләтнең территориясе этносоциаль һәм географик принциплар буенча дүрт көнбатыш «як»ка (Арча, Тау, Болын һәм Уңъяк яр якларына) һәм алты көнчыгыш «җир»ләргә (Башкорт, Агыйдел, Вотяк, Кама, Костяк һәм Сыпла/Ципла җирләренә), административ-сәяси җәһәттә үзәк хан биләмәсенә («Болгар вилаяте») һәм ким дигәндә биш даруга (Алат, Арча, Гәреч, Җөри һәм Нугай даругаларына) бүленгән. Казан дәүләтендә X–XIV гасырларда ук нигезләнгән кирмәннәр, авыллар һәм шәһәрләр күп булган (700 дән артык). Ханлыкның сәяси һәм мәдәни-икътисади үзәкләре – Казан, Алабуга, Арча, Болгар, Җөри, Иске Казан, Кашан, Тәтеш, Чаллы шәһәрләрендә тормыш кайнап торган. Илдә төрки телле татарлар, башкортлар, чувашлар, нугайлар һәм фин-угор телле марилар, мордвалар, удмуртлар – җәмгысе 450 меңләп кеше яшәгән. Ханлык тормышында рус кенәзлекләре, Урта Азия һәм Кавказ илләре белән сәүдә-икътисади бәйләнешләр мөһим роль уйнаган.

Мәскәү һәм Казан арасында Алтын Урданың территориаль мирасы, Идел-Урал төбәгендә хакимлек итү өчен дистәләрчә еллар дәвамын-

да барган кискен көрәш 1552 елның икенче октябрендә Казанның яулануы белән төгәлләнә. 1556 елда татар ханлыгының барлык төп территориясе Мәскәү дәүләте составына кертелә.

«Болгавыр заман» елларында (XVI гасыр ахыры – XVII гасыр башы) формаль рәвештә һаман да «Казан патшалыгы» (1917 елга кадәр Россиянең барлык идарәчеләре титулларында чагылыш таба) дип аталган Казан төбәге асылда Мәскәүдән аерымлана. Казан феодаллары югары катлавының бер өлешендә җирле рус аксөякләре җитәкчелегендә аерым дәүләт төзү нияте туа. Казанда әлеге сәяси болгавырлык 1613 елга кадәр, Михаил Романовны патша итеп сайлаганчы дәвам итә.

1708 елда Казан губернасы төзелә, аның составына Урта Идел буе һәм Көнбатыш Урал алды керә. Казан Россия империясенең мөһим административ һәм сәнәгый үзәкләренең берсенә әверелә.

XVIII–XIX гасырлар чигендә капиталистик мөнәсәбәтләр үсеше, милли буржуазия формалашу, Урта Идел буе һәм Көнбатыш Урал алды татарларының социаль-икътисади тормышындагы үзгәрешләр татар мәгърифәтчелеге яралышы һәм үсеше өчен нигез хасил итә. Татар мәгърифәтчелек фикеренең аеруча үсеш алган чоры XIX гасырның икенче яртысына туры килә. Ул татар җәмгыяте алдынгы көчләренең халык тормышын үзгәртүгә көчәя барган омтылышын чагылдыра, бу исә яңа иҗтимагый мөнәсәбәтләр үсешенә һәм ныгуына булышлык итә.

XIX гасырның икенче яртысында – XX гасыр башында уздырылган хөкүмәт реформалары илдә буржуаз мөнәсәбәтләр темпларының тизләнеше өчен шартлар тудыра. Татарларда яңа капиталистик элита оешу милли үзаң күтәрелешенә һәм XIX–XX гасырлар чигендә хәзерге татар милләтенең тәмам формалашып җитүенә этәргеч бирә. Шулай итеп, хәзерге татар халкының һәм хәзерге Татарстанның күпгасырлык тарихы бар, әлеге мәкаләдә мин шул тарихның мөһим бер чорын гына кыскача бәян итәм.

1

Евразиянең чиксез, меңнәрчә чакрымнарга җәелгән далалары... Дистәләрчә гасырлар дәвамында алар көнбатыш һәм көньяк тарафларга күчмәннәрнең – «дөньяны тетрәтүчеләр»нең күпсанлы халыкларны хәрәкәткә китергән яңа дулкыннарын – әледән-әле территориаль җәһәттә гигант яисә гаять зур дәүләти берләшмәләр төзегән скифларны, сарматларны, күктөрекләрне, хәзәрләрне, болгарларны, гузларны (угызларны), бәҗәнәкләрне, кыргызларны, кимәкләрне, кыпчакларны һәм башка кабиләләрне чайпалдырып чыгардылар. Әлеге борынгы һәм урта гасырлардагы кабиләләр һәм дәүләтләр хакындагы язма чыганаклар минем тарафтан «Йөзьеллыклар төпкеленнән» («Из глубины столетий» – Казань, 2000/2004), «"Скифлар" тарихы замандашлар күзлегендә» («История "скифов" глазами современников» – Казань, 2001), «Хәзәрләр һәм аларның вассаллары замандашлар күзлегендә» («Хазары и их вассалы глазами современников» – Казань, 2014) фәнни-популяр җыентыкларында тәкъдим ителгән иде инде.

XIII гасырда Евразиянең дала киңлекләре янә, мөгаен, җәелеш һәм нәти-

җәләр нисбәтендә Халыкларның бөек көчеше белән генә чагыштырырлык гаять зур тарихи вакыйгалар мәйданына әверелә. Үзәк Азия далаларында күпсанлы төрки-монгол кабиләләре Чыңгыз хан титулына һәм беркадәр вакыттан соң үз империясенә «Yeke mongol ulus» («Бөек монгол дәүләте») атамасы биргән көчле ихтыярлы Тимучжин (яшәгән еллары: 1155/1162–1227) кул астында берләшәләр. Әлеге чор бәян ителгән язма чыганаклар һәм аларны анализлау югарыда күрсәтелгән басмаларда, шулай ук Тимучжинның тууына 850 ел тулуга бәйле рәвештә 2002 елда Казанда басылган «Чыңгыз хан – 850» («Чингиз-хан – 850») китабымда урын алды.

2019 елда кайчандыр бердәм булган Монгол империясенең иң зур «кыйпылчык»ларының берсе – Алтын Урданың 750 еллыгы билгеләп узылды. Хәзерге тарих фәнендә әлеге дәүләтнең башлыча ике исеме – «Алтын Урда» һәм «Җүчи Олысы» атамасы кулланыла. Икенче очракта бу традиция шәркый чыганаклардан алынды, беренче атама исә XVI гасырның икенче яртысына – XVII гасырның башына нисбәтле рус тарихи-публицистик әдәбиятыннан кертелде.

Җүчи Олысы Евразиянең урта гасырлар тарихында гаять зур роль уйный, шактый дәрәҗәдә шунда яшәгән халыкларның һәм соңрак барлыкка килгән дәүләтләрнең алга таба үсеш юлларын билгели. Ул ифрат зур территорияне били, аның биләмәләре көнчыгышта Иртеш елгасыннан көнбатышта Дунай елгасына кадәр, төньякта Ак диңгездән көньякта Кара диңгезгә һәм Каспий диңгезенә кадәр җәелә. Чыңгызыйлар-Җүчиләр озак дәвергә үз хакимиятләре астында төрле мәдәниятләргә, хуҗалык итү хасиятләренә һәм сәяси хакимият оешу формаларына ия күпсанлы халыкларны берләштерүгә ирешәләр.

Безнең очрактан (Алтын Урда тарихы) гайре, башка берәр дәүләтнең үткәненә карата фәнни бәхәсләр кискенрәк фасылга кергән очраклар сирәктер, мөгаен. Әлеге бәхәсләргә этәргән фәнни факторлар белән беррәттән фәнгә кагылышы булмаган факторларның да роле зур. Илебез тарих фәнендә империя һәм совет чорларындагы идеологик юнәлешләр, күрсәтмәләр Җүчи Олысының Евразия халыклары тарихындагы ролен һәм урынын фәнни кимәлдә ачыклау һәм бәяләү юлында тикшерүчеләрнең мөмкинлекләрен катгый чикләделәр. Әлеге чорларда нәшер ителгән хезмәтләрдә Алтын Урда тарихы башлыча аның дөнья цивилизациясенә тискәре йогынтысы яссылыгында яктыртылды. Бу урында ВКП(б) Үзәк Комитетының 1944 елның тугызынчы августында кабул ителгән яманатлы «Татарстан партия оешмасында масса-политик һәм идеология эшенең торышы һәм аны яхшырту чаралары турында» карарын аерым искә алып узу зарур, ул СССРда Чыңгызыйлар-Җүчиләр дәүләте тарихын фәнни өйрәнүгә һәм тикшерүгә гаять зур зыян китерде.

Рәсми идеологик күрсәтмәләргә карамастан революциягә кадәрге дәвердә һәм совет чорында Алтын Урда тарихын объективлык һәм тарихилык принципларыннан чыгып өйрәнгән галимнәрнең искәрмә сыйфатында аз булуы гаҗәп түгел. Алар арасында Никита Бичурин (1777–1853), Осип Ковалевский (1801–1878), Михаил Иванин (1801–1874), Гордий Саблуков (1803–1880), Василий Григорьев

(1816–1881), Илья Березин (1818–1896), Доржи Банзаров (1822–1855), Василий Радлов (1837–1918), Василий Бартольд (1869–1930), Борис Владимирцов (1884–1931), Николай Трубецкой (1890–1938), Мөхәммәд Сәфәргалиев (1906–1970), шулай ук Лев Гумилев (1912–1992) исемнәрен искә алу аерым игътибарга лаек. XIX гасырда Алтын Урда хакында шәркый чыганаклар мәгълүматларын җыю буенча күренекле чыганаклар белгече Владимир Тизенгаузен (1825–1902) ифрат зур эш башкара. Ул үзе җыйган мәгълүматларны ике китапка туплый, 1884 елда «Алтын Урда тарихына нисбәтле материаллар җыентыгы»ның беренче томын бастырып чыгара. Галим тарафыннан әзерләнгән икенче том, аның вафатыннан соң дүрт дистә еллар чамасы узгач кына, 1941 елда дөнья күрә. Совет чорында Җүчи Олысын һәм Алтын Урда мирасын өйрәнүгә Казан тарихчысы, шәркыятьче галим, атаклы чыганаклар белгече Миркасыйм Госманов (1934–2010) зур өлеш кертә.

1950–1980 елларда Урта һәм Түбән Идел буйларында уздырылган археологик тикшеренүләр Алтын Урда тарихын өйрәнүдә аерым юнәлешкә әверелә; алар революциягә кадәр яшәгән этнограф һәм археолог Александр Терещенконың (1806–1865) һәм Гражданнар сугышы елларында Алтын Урданың матди мирасын өйрәнгән Франц Баллодның (1882–1947) фәнни эзләнүләренең дәвамы булып тора. Археология фәненең үзенчәлеге билгеле бер дәрәҗәдә галимнәргә теманың кискен сәяси-идеологик «почмаклар»ын урап узарга мөмкинлек бирә. Казу эшләре (аерым алганда, Мәскәү дәүләт университеты профессорлары Алексей Смирнов (1899–1974) һәм Герман Фёдоров-Давыдов (1931–2000) җитәкчелегендә алып барылган тикшеренүләр) нәтиҗәсендә Алтын Урда җәмгыяте тормышының төрле якларын чагылдырган гаҗәеп бай фактик материал туплана.

Революция алдыннан, аннан соң эмиграциядә Россия зыялылары даирәсендә Россия цивилизациясе үзенчәлеген аңлауның һәм кабул итүнең евразиячел концепциясе формалаша. Евразиячеләр Алтын Урданың Русьта барган процессларга зур һәм, иң мөһиме, уңай йогынтысын таныйлар. Евразиячеләрнең төп идеологларының берсе Петр Савицкий (1895–1968) «Иске Дөньяның гаять зур өлешен яулауга һәм идарә итүгә ирешкән монгол-татарлар (Чыңгыз хан һәм аның варислары) дәүләтчелеге мисалы, һичшиксез, бөек рус дәүләтчелеген булдыруда зур һәм уңай роль уйнады», – дип саный. Шунысы игътибарга лаек, совет фәне тарафыннан танылмаган евразиячел концепция Көнбатышта актив дәвамчыларын таба.

Җүчи Олысы тарихы исемнәре революциягә кадәр киң танылган татар тарихчылары Шиһабетдин Мәрҗани (1818–1889), Морат Рәмзи (1854–1934), Ризаэтдин Фәхретдин (1859–1936) һәм башкаларның хезмәтләрендә дә яктыртыла. Аларда Алтын Урда татар халкы тарихында мөһим чор хасил иткән югары үсешле һәм мәдәниятле дәүләт буларак тасвирлана. Алга таба Җүчи Олысының ролен һәм әһәмиятен фикерләүдәге әлеге юнәлеш 1917 елның октябреннән соң чит илләргә киткән татар галимнәре, аерым алганда, Габделбари Баттал (1880–1969), Әкъдәс Курат хезмәтләрендә үстерелә.

Илебез тарих фәнендә Алтын Урда тарихын фикерләүдә тамырдан үзгәрешләр совет сәяси системасы таркалганнан соң гына мөмкин булды. Яңа шартларда, фәннилек һәм әтрафлы уйланган мөнәсәбәт принципларына нигезләнеп, бер яктан, Урда йогынтысының гүяки җимергеч нәтиҗәләренә басым ясаудан, икенче яктан, утрак һәм күчмә халыкларның үзара бәйланышларын идеаллаштырудан гыйбарәт чиктән-чиккә тартылулы фикерләрдән тайпылып, галимнәр партиячел-идеологик киртәләрдән арынуга ирештеләр һәм Алтын Урда тарихын яңа күзлектән карау яссылыгына чыктылар. Мәсәлән, Урта Идел буеның урта гасырлар археологиясе һәм тарихы буенча Россиядә зур белгеч, болгар-татар археологик истәлекләренең тулы җыелмасын (әлеге хезмәт Идел-Чулман Болгарстаны, Алтын Урданың Болгар олысы һәм Казан ханлыгы тарихи топографиясен өйрәнү өчен нигез хасил итә) булдыручы һәм алты томлы «Татарстан Республикасының археологик картасы»н эшләүчеләрнең берсе, тарих фәннәре докторы Равил Фәхретдинов (1937–2014) шул елларда татарларның килеп чыгышы һәм этник тарихы буенча үзенең «болгарчылык» концепциясен яңадан кайтып карады, нәтиҗәдә аның фикере тирән үзгәреш кичерде. 1990 елларда һәм 2000 еллар башында Алтын Урда тарихына бәйле шактый гына кызыклы һәм тирән эчтәлекле хезмәтләр дөнья күрде.

Евразиячеләрнең йогынтысыннан тыш, чит илләрдә теманы өйрәнү тарихы Көнбатышның традицион шәркыять гыйлеме кысаларында формалашты. Бу очракта әлеге юнәлешнең классик вәкиле Бертольд Шпулер (1911–1990), шулай ук Алтын Урда тарихы буенча хәзерге вакытта актив тикшеренүчеләрнең берсе Юлай Шамил углы исемнәрен атамыйча мөмкин түгел.

Хәзерге чорда әлеге өлкәдә эшләүче Россия һәм чит илләр галимнәре арасында актив рәвештә фикер алышу һәм үзара хезмәттәшлек җәелә бара. Яңарак кына нәшер ителгән фундаменталь коллектив монографияләр (мәсәлән, җиде томлык «Иң борынгы заманнардан татарлар тарихы»ның өченче томы, рус һәм инглиз телләрендәге «Дөнья тарихында Алтын Урда») һәм халыкара конференцияләр (аерым алганда, 2019 елда Франциядә, Россиядә, Казахстанда һәм Төркиядә уздырылган конференцияләр) шундый хезмәттәшлекнең нәтиҗәле булуын ачык күрсәтәләр.

## 2

Җүчи Олысының (Алтын Урданың) тарих башы аерылгысыз рәвештә XII гасыр ахырында – XIII гасыр башында Үзәк Азиядә булып узган вакыйгалар белән бәйле. Әлеге чорда, шул төбәктә көчәнеп яшәгән татар-монгол кабиләләрендә феодаль мөнәсәбәтләр ныгый барган шартларда, аларның югары катлау аксөякләре арасында хакимлеккә ирешү өчен көрәш җәелә. Бу көрәштә «кара татарлар» (монголлар) юлбашчыларының берсе – Тимучжин җиңүгә ирешә һәм 1206 елда төрки-монгол аксөякләренең Онон елгасы буенда уздырылган корылтаенда ул бөек хан – Чыңгыз хан дип игълан ителә (бүгенге көндә «Чыңгыз хан» титулы галимнәр тарафыннан «диңгездәй чиксезлек хакиме» мәгънәсендә аңлатыла). Чагыштырмача кыска вакыт эчендә Алтай һәм Себер халыклары монгол-татарлар

(бу атама, күпләр уйлаганча XIX гасыр авторлары Христиан Крузе һәм Пётр Наумов уйдырмасы булмыйча, язма чыганаклар буенча XIII гасырның беренче утызъеллыгыннан ук мәгълүм) хакимияте астына әләгә, Кытай империясе, Урта Азия, Иран һәм Кавказ арты территорияләре буйсындырыла.

Теләсә кайсы яулар илбасарлар юлында калган халыкларга исәпсез бәлаләр һәм котычкыч зыян китерә. Әлеге җәһәттә монгол-татар яуларының нәтиҗәләре дә искәрмә булмый. Әмма башка яубасарлар гамәлләреннән үзгә хәлдә, монгол-татарлар буйсындырылган территорияләрдәге рухи кыйммәтләрне һәм тормыш рәвешен юк итәргә омтылмыйлар. Алай гына да түгел, әле оешкан чорында ук Монгол империясендә кайбер мөһим үзенчәлекләр хөкем сөрә, шуларның берсе – яуланган халыкларның диненә һәм мәдәниятенә карата толерантлык, ягъни сабырлык мөнәсәбәте, билгеле бер очракларда – яуланган халыкларның мәдәни казанышларын кабул итү, үзләштерү. Әлеге тенденция ул чорда дөнья цивилизациясенең гаять зур үзәге булган Кытайга карата мөнәсәбәттә аеруча ачык чагыла. Бу очракта хәрби һәм мәдәни өлкәләр белән генә чикләнмичә, монгол-татарлар кытайларның күпгасырлык дәүләт белән идарә итү тәҗрибәсен дә үзләштерәләр.

Монгол империясе субъекты буларак Җүчи Олысының барлыкка килү чоры Чыңгыз хан идарәсе заманына барып тоташа. Гаять зур дәүләте формалашу процессында ук ул илне олысларга бүлә, төп олысны үзенә калдыра, кырыйдагы ике олысны вассаллык шартларында уллары Җүчигә һәм Чагатайга тапшыра. (Аның вафатыннан соң тагын бер олыс – оныгы Һулагу биләмәсе барлыкка килә.) Чыңгыз хан үзенең варисы итеп өченче улын – Үгәдәйне билгели, ә өлкән улы Җүчигә (яшәгән еллары: 1184–1227) исә күпчелек өлеше әлегә яуланмаган көнбатыш территорияләрне васыять итә. 1227 елда Җүчи вафат булганнан соң, Чыңгыз ханның шәхси әмере белән 1228/1229 елда узган бөтенмонгол корылтаенда олысның хуҗасы булып Җүчинең улы Бату (яшәгән еллары: 1209 тирәсе – 1255/1256) раслана. Олысның яуланмаган өлешен 30 мең кешелек гаскәре белән нәкъ менә ул буйсындырырга тиеш була. 1229–1230 елларда Бату һәм аның бертуганнары кыпчакларга һәм Идел болгарларына каршы «Саксин өлкәсе»нә яу оештыралар, ләкин ул уңышсыз тәгәлләнә. Бу урында укучының хәтеренә төшереп узыйм, монгол-татарлар Сүбәдәй һәм Җәбә җитәкчелегендә Калка елгасы буенда җиңүгә ирешкәннән соң, 1223/1224 елда Идел болгарлары тарафыннан тар-мар ителәләр. Шул чорда яшәгән Ибне әл-Әсир түбәндәгечә хәбәр итә: «Русларга карата без сөйләгән гамәлне кылганнан соң һәм аларның җирләрен бөлдергәч, татарлар ул яктан кайттылар һәм 620 ел ахырында [һиҗри] Болгарга юнәлделәр. Болгарда яшәүчеләр аларның якынлашуы хакында белеп алгач, берничә урында поскаклар (засадалар. – *Б.Х.*) кордылар, татарларга каршы чыктылар, алар белән очраштылар да, аларны поскаклар урынына алдап алып керделәр; [шуннан соң] тылдан һөҗүм иттеләр, татарлар уртада калды, аларны һәр тарафтан кылыч кырды, күпләр үтерелде һәм аларның бик азы гына исән калды. Әйтүләренчә, алар [исән калганнар – ?] дүрт меңләп ке-

ше булган. Алар шуннан, Саксин аша, үз патшалары Чыңгыз хан янына кайттылар, һәм кыпчаклар җире алардан бушап калды; аларның исән калганнары үз җирләренә кайтты...» 1232 елда монгол-татарлар кабат Идел-Чулман Болгарстанының (бу вакытта инде ул феодаль таркаулык хәлендә булган) көньяк-көнчыгыш өлешенә бәреп керәләр, ләкин алар юлын яхшы ныгытылган Биләр кирмәне («Бөек шәһәр», элек бердәм дәүләт башкаласы) бүлеп тора, Азиядән килгән яугирләр аны камарга җөрьәт итмиләр. Югарыда күрсәтелгән вакыйгалар (Идел болгарлары тарафыннан җиңелүләр) көнбатышта яңа җирләр яулау мәсьәләсен гомумдәүләт дәрәҗәсенә күтәрүгә сәбәп була, әлеге ниятне Монгол империясенең бөек ханы Үгәдәй шәхсән хуплый. Барлык империянең хәрби көчләрен җәлеп итү Бату армиясен шактый зурайтуга һәм көчәйтүгә мөмкинлек бирә, галимнәр аның составында 50–120 мең чамасы кеше булган дип исәплиләр. Урта гасырлар тарихчысы Галәветдин Җүвәйни болай дип яза: «Каган [Үгәдәй] икенче мәртәбә Бөек корылтай җыйгач, алар [ханзадәләр] [әлегәчә] буйсындырылмаганнарның барчасын кырып бетерү һәм буйсындыру хакында киңәштеләр. Бату биләмәсенең янәшәсендәге әлегәчә буйсындырылмаган һәм шәһәрләренең күплеге белән масайган Болгар, Ас һәм Рус җирләрен яулау хакында карар кабул ителде. Батуга булышу өчен һәм ярдәмгә ул [Үгәдәй] ханзадәләрдән Мәнгү ханны һәм аның бертуганы Бүчәкне, үз улларыннан – Гөек ханны һәм Кадаганны, башка ханзадәләрдән – Кулканны, Бурине, Байдарны, Батуның бертуганнары Хордуны һәм Тангутны һәм башкаларны, абруйлы әмирләрдән Сүбәдәй-баһадурны билгеләде. Гаскәрләр урнашуга карап, барлык ханзадәләр дә урыннарына китеп бардылар, яз җиткәч үз биләмәләреннән чыктылар һәм [эшне башларга] ашыктылар. Болгар чикләрендә ханзадәләр бергә җыелдылар. Аларның гаскәрләре күплегеннән җир калтыранды һәм аларның гаскәрләренең күп санлы булуыннан һәм шау-шу куптаруыннан хәтта кыргый җәнлекләр катып калды...».

Шулай итеп, 1236 елның көзендә монгол-татарлар Европаны яулауга кузгалалар, һәм Идел-Чулман Болгарстаны кабат алар юлында җитди көч булып тора. Илбасарлар Биләрне штурм белән алалар, башка болгар шәһәрләрен һәм авылларын кулга төшерәләр; XIII гасыр уртасына әлеге төрки дәүләтнең барлык территориясе Җүчи Олысы составына керә. Урта һәм Түбән Идел буендагы мукшылар, бортаслар һәм кыпчаклар буйсындырылганнан соң, һәлакәт чираты сәяси таркау рус җирләренә килеп җитә. 1237 елда монгол-татарлар – Рязань кенәзлеге гаскәрләрен, 1238 елда Төньяк-көнчыгыш Русьның берләштерелгән гаскәрләрен тар-мар итәләр. 1239–1240 елларда Көньяк-көнбатыш Русь та – Переяславль, Чернигов, Киев һәм Галич-Волынь кенәзлекләре яулана. Рус җирләрен басып алгач, монгол-татар гаскәрләре Европага юнәлә. Польша, Чехия, Венгрия, Хорватия бөлдерелә. Әмма Әдрән диңгезгә килеп чыкканнан соң, монгол-татарлар Босния, Сербия һәм Дунай Болгариясе аша кайту юлына борылалар. Батуның әлеге карарга килүе сәбәпләре арасында еш кына бөек хан Үгәдәйнең вафаты һәм Батуның Каракорым-

да бөек хан сайлауда катнашу теләге күрсәтелә. Моннан тыш, инде яуланган территорияләрне буйсынуда тоту зарурлыгы туа, көнбатыш тарафта яуларны дәвам итүнең бу мәсьәләне катлауландырачагы аңлашыла. Аннан соң, көнбатышка яуларны дәвам итүгә тагын бер тоткарлык туа – Киев яуланганнан соң, Үгәдәй әмере белән, Бату гаскәрләреннән аеруча әзерлекле Гөек һәм Мөнкә төмәннәре аерып алына.

1240 еллар башында Бату гаскәрләренең бер өлеше Монголиягә әйләнеп кайта, икенче өлеше Идел буенда кала. Батуны шунда калырга этәргән төп сәбәпләрнең берсе хәрби-стратегик мәгънәгә ия – Идел буенда урнашып буйсындырылган халыкларны һәм территорияләрне контрольдә тоту уңайлы була. Шулай итеп, Бату хан заманында яңа дәүләт оеша. Шунысы игътибарга лаек, Бату хан үзенең тәүге башкаласы сыйфатында хәзерге Татарстан Республикасы территориясендәге Болгар шәһәрен файдалана. Соңрак, Бәркә хан (яшәгән еллары: 1209–1266) чорында да Болгар Җүчи Олысының җәйге башкаласы булып кала. Бу хакта, мәсәлән, Гильом де Рубрук һәм Марко Поло, шулай ук XVI гасыр уртасында иҗат ителгән елъязма-публицистик хикәятнең аноним рус авторы да искә алалар [*бу хакта 2002 елда «Казан ханлыгы халыклары: этносоциологик тикшеренү» хезмәтебездә искәреп узган идек*]. Әлеге язма мәгълүмат нумизматик факт – Болгарның Алтын Урданың тәүге акчалары сугылу урыны булуы белән дә раслана. Болар барысы да татарларның тарихи хәтерендәге Болгарның «бөек ханнар җәсәдләре урнашкан Алтын тәхет» белән тәңгәл бәйләнешенә китерә. Шунысын да билгеләп узыйм, XVI гасырда «Казан тарихы»ның рус авторы да Казанның нигезләнүен ниндидер «Болгарлы Саин патша»га («царь Саин Болгарский») кайтарып калдыра. Югыйсә, урта гасырлар язма чыганакларында нәкъ менә Бату ханның «Саин» («мәрхәмәтле», «гадел», «игелекле») буларак олылануы безгә мәгълүм ләбаса – бу хактагы мәгълүматларны Марко Поло, Григор Акнерци, Рәшидетдин, Мәкризи, Нүвәйри, Вассаф, Ибне Биби язмаларында очратабыз.

Бату идарә иткән заманда (1242–1256) Җүчи Олысы суверен дәүләт булмый әле, ул Бөек монгол дәүләтенең («Yeke mongol ulus») бер өлешен тәшкил итә. Бу факт Җүчи Олысында бөек хан Мәнгү исеменнән акчалар сугылуда, салымнарның һәм ясакның күп өлеше империя үзәгенә озатылуда, олысның хан тәхетенә утыртылачак варис кандидатурасын Каракорымдагы хакимият белән килештереп билгеләүдә һәм башкаларда ачык күренә.

Бердәм Монгол империясе кысаларында туплану, берләшү монгол-татар аксөякләренә беренче чиратта киң колачлы яулап алуларны дәвам итү өчен кирәк була. Ләкин яулар тәмамланып, тыныч тормыш башлангач, буйсындырылган гаять зур һәм төрле территорияләрне бердәм идарә итү һәм контрольдә тоту ифрат катлаулана. Тыныч хуҗалык-иҗтимагый процесслар, илбасарларның яуланган халыклар белән мәдәни якынаюы барышында, монгол яуларына кадәрге җирле традицияләрнең яңарышы һәм ныгуы, килмешәк идарәчеләргә аларга яраклашырга туры килүе нәтиҗәсендә сәяси, хуҗалык һәм мәдәни тормышның локаль үзенчәлекле формалары барлыкка килә. Торган

саен идарә җепләре системасы аерым олыслар дәрәҗәсендә һәм кысаларында туплана бара, империя башкаласы Каракорымнан идарә иткән каганның («ханнар ханы»ның, «бөек хан»ның) хакимияте һәм химаясе чынлыкта файдасыз һәм кирәксез мәшәкатькә әверелә, җирле хакимият эшчәнлегенә комачау тудыра, аның авырлыгы олыс идарәчеләрен һәм төбәк аксөякләрен баса төшә. Монгол империясе формалашуы төгәлләнүе вакытына каган олысы – Монголия һәм Кытай, Чагатай Олысы – хәзерге Урта Азия (тулысынча Көнчыгыш һәм Көнбатыш Төркестан), Һулагу Олысы Иран, Әфганстан, Көньяк Кавказ арты һәм Месопотамия территорияләрен колачлый. 1219–1224 елларда Җүчинең элгәреге биләмәсеннән (ул 1207–1208 елларда буйсындырылган Енисей кыргызлары һәм Себернең көньягында яшәгән «урман халыклары» җирләреннән башлангыч ала) хасил булган, көнчыгыштан көнбатышка таба Алтайдан Дунайгача, көньяктан төньякка таба Аралдан Уралгача җәелгән бәйле территорияләрне (Иртеш буе, Саян-Алтай таулыгы, Көнбатыш Себер, Арал буе һәм Урал яны, Түбән һәм Урта Идел буйлары, Төньяк Кавказ, Дон буе, Кара диңгез буйларының төньягы, Днестр буе, шулай ук Көнчыгыш Европа тигезлегенең төньяк-көнчыгыш өлеше) үз эченә алган Җүчи Олысы дәүләтнең көнбатыш өлешен тәшкил итә. Үзәк хакимиятнең көчсезләнүе һәм Каракорым тәхете өчен барган үзара низаглар 1269 елда Җүчи, Чагатай һәм Һулагу олыслары башлыкларының үзен бөек хан дип игълан иткән Хубилайны танудан баш тартуларына, аларның үз биләмәләре чикләрен тәгаенләвенә, шул рәвешчә бердәм Монгол империясенең тәмам таркалуы расланып, аның яшәеше чикләнүгә китерә.

Юань Кытаенда (Хубилай яңа Юань династиясен нигезли, үз башкаласын Каракорымнан Ханбалыкка – хәзерге Пекинга күчерә) һәм Һулагулар Иранында чагыштырмача тиз арада, Урта Азиядә (Чагатай Олысы) бераз соңрак (90–120 елдан соң) Чыңгызыйлар династияләре бәреп төшерелә, монгол-татарлар тарафыннан оештырылган сәяси һәм иҗтимагый институтлар асылда тулысынча юкка чыгарыла, элеккеге куәт һәм йогынты сүрелә. Җүчиләрдә исә барысы да элеккечә саклана, аларның төрле чорларда алты–сигез миллион квадрат километрлы территорияне иңләгән олысы арада иң зурысы була. Минем фикеремчә, нәкъ менә шуңа күрә Җүчи Олысын Монгол империясенең куәтен саклаган төп варисы, скифлар заманнарыннан башлап исәпләгәндә бөек дала империяләренең иң соңгысы буларак бәяләү урынлы. Ул иҗтимагый хәтергә төрле милли һәм тарихи традицияләрдә кабул ителгәнчә, төрлечә аталышта – Җүчи Олысы яисә Олуг Олыс, Дәште Кыпчак яисә Команнар иле (Комания), Бәркә Олысы яисә Мәмләкәте Үзбәк, Татарлар дәүләте яки Бөек Татария һәм, ниһаять, Урда яки Алтын Урда буларак кереп калды. Минемчә, соңгысы – илебез һәм чит ил тарих фәнендә аеруча киң кулланылучы, әлеге дәүләтнең бөеклеген һәм куәтен күпкә тулырак чагылдыручы атамадыр, мөгаен.

*Дәвамы бар*

2001 елның августыннан чыга

# Мәйдан

№5 (234)
МАЙ /2021

Гамәлгә куючы:
«Татмедиа» акционерлык җәмгыяте
(420097, Казан, Академиклар урамы, 2)

Баш редактор Рөстәм Госман улы ГАЛИУЛЛИН

РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:

**Әлфия ӘДИЯТОВА** (Казан)
**Фирдүсә ӘЮПОВА** (Чаллы)
**Дилбәр БУЛАТОВА** (Уфа)
**Разил ВӘЛИЕВ** (Казан)
**Фәридә ГАБИДУЛЛИНА** (Алабуга)
**Рафаил ГАЗИЗОВ** (Мамадыш)
**Фоат ГАЛИМУЛЛИН** (Казан)
**Рөстәм ГАНИЕВ** (Түбән Кама)
**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА** (Казан)
**Илдус ЗАҺИДУЛЛИН** (Казан)
**Наил МӘҺДИЕВ** (Чаллы)
**Илдар МИРГАЛИМОВ** (Казан)
**Рүзәл МӨХӘММӘТШИН** (Казан)
**Фоат САДРИЕВ** (Мөслим)
**Ркаил ЗӘЙДУЛЛИН** (Казан)
**Факил САФИН** (Чаллы), редакция советы рәисе
**Равил ФӘЙЗУЛЛИН** (Казан)
**Энгель ФӘТТАХОВ** (Актаныш)
**Рамил ХӘЛИМОВ** (Чаллы)
**Рәфкать ШАҺИЕВ** (Әлмәт)
**Әнвәр ШӘРИПОВ** (Чаллы)
**Рафаэль ЮНЫСОВ** (Чаллы)

РЕДАКЦИЯ КОЛЛЕКТИВЫ:

иҗат төркеме:

**Факил САФИН** (баш редактор урынбасары)
**Лилия ГЫЙБАДУЛЛИНА** (шигърият бүлеге)
**Гөлшат ИЛАЛЕТДИНОВА** (җаваплы секретарь)
**Светлана ФӘИЗОВА** (проза бүлеге)
**Гөлнар КАРАЕВА** (сайт редакторы)
**Сәмәрә ХӘЙРУЛЛИНА** (гомуми бүлек редакторы)

гамәли хезмәткәрләр:

**Резеда ГАТИНА** (баш бухгалтер)
**Индира ВӘЛИЕВА** (компьютерда биткә салу операторы)

Идел буе регионында Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәте идарәсендә ПИ № ФС77-76913 саны белән 2019 елның 1 октябрендә теркәлгән. Журналның индексы – П2356.
Редакция һәм нәшрият адресы: 423827, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Яшь ленинчылар бульвары, 9 нчы йорт (27/19), «Мәйдан». Телефоннар: (8552) 59-75-84, 59-65-84.
E-mail: **maydan06@mail.ru**, сайт адресы: **maydan.tatar**
Җыярга тапшырылды: 30.03.21. Басарга кул куелды: 30.04.21. Компьютерда җыелды. Катнаш гарнитура. Офсет ысулы белән басылды. Күләме – 10,0 басма табак.
Форматы: 70х100/16. Тиражы – 1583 данә. Заказ – Е-1385.
Ярты елга язылу бәясе – 507 сум.

Кульъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый. Редакция фикеренә тәңгәл килмәгән язмалар да басыла. Күчереп басканда «Мәйдан»нан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри. Авторларның язмаларында табылган хаталар һәм кимчелекләр өчен редакция җавап бирми. 6+

«Татмедиа» акционерлык җәмгыяте филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2.

© «Мәйдан», 2020.

| | | |
|---|---|---|
| **Татар шигыре** | 3 | Гамил АФЗАЛ. **«Аю йөргән урман арасында...»** |
| | 4 | **Туган авыл белән саубуллашу** |
| **Чәчмә әсәр** | 5 | Хәбир ИБРАҺИМОВ. **Кызыл утрау** |
| **Шигъри гөләндәм** | 36 | Ренат ХАРИС. **Кеше – вакыт** |
| **Чәчмә әсәр** | 40 | Әлфия СИТДЫЙКОВА. **Диңгез суы тозлы ул** |
| **Яшьләр иҗаты** | 75 | Алмаз МАНСУРОВ. **Мин – якты эз** |
| **Тарих** | 79 | Булат ХӘМИДУЛЛИН**. Алтын Урда һәм аның тарихи мирасы** |
| | 94 | Вахит ИМАМОВ. **Ачы күз яшьле җиңү** |
| | 97 | **Севастопольның соңгы каһарманы** |
| | 100 | **Татар улы Шакирҗан** |
| **Тормыш һәм гамь** | 103 | Рәзинә МӨХИЯР. **Караидел саллары** |
| **Чаллы хикәяләре антологиясе** | 108 | Альберт САФИН. **Җыр** |
| | 114 | **Юлда** |
| **Яңа китап яктысы** | 121 | Лилия ГЫЙБАДУЛЛИНА. **Канатлы шигърият** |
| **Юбилей** | 125 | Эльверт ХАМАТШИН. **Күңелләрдә моң чаңы** |
| **Тормыш һәм гамь** | 128 | Хәлим СӘЛӘХОВ. **Язмышлардан узмыш юктыр...** |
| **Татарстанда Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы** | 133 | Мирсил ӘҺЛЕТДИНОВ. **Актаныш музейлары** |
| **Шаян сәхифә** | 138 | Гамил АФЗАЛ. **Өф-өф итеп...** |
| **Әдәби-иҗтимагый тормыш** | 143 | |
| **«Мәйданчык» кушымтасы** | 145 | Лилия ФӘТТАХОВА. **Бизнесмен Шүрәле** |

Тышлыкның 1 нче битендә – Шәрип Шәймиев музей-йорты, Актаныш районы Әнәк авылы




Булат ХӘМИДУЛЛИН

# Алтын Урда һәм аның тарихи мирасы*

3

Җүчи Олысының Монгол империясеннән тулысынча аерылып чыгуы Батуның оныгы Мәнгү Тимер хан (идарә иткән еллары: 1266–1280) чорына туры килә. Бәркә ханның Алтын Урданың үзәктән бәйсезлеккә ирешүенә юнәлеш тоткан сәясәтен дәвам итеп, ул Урда ханнарыннан беренче буларак, 1266/1267 (һиҗри 665) елда үз исеменнән һәм «гадел хөкемле бөек хан» титулын күрсәтеп, Болгарда һәм Биләрдә, Сарайда һәм Кырымда, Харәземдә һәм Үкәктә акчалар суктыра, шулай ук үз ярлыкларын тапшыра башлый – бу фактлар Җүчи Олысының ачыктан-ачык мөстәкыйльлеккә дәгъваларын чагылдыра. Алтын Урданың суверенлыгы юридик җәһәттә чыңгызыйларның һәм монгол-татар нойоннарының 1269 елда Урта Азиядәге Талас елгасы буенда уздырылган корылтаенда рәсмиләштерелә.

Һичшиксез, Монгол империясе кебек үк, Алтын Урда хәрби көч куллану нәтиҗәсендә һәм нигезендә оеша. Таш-

* Дәвамы. Башы 4 нче санда

кын сыман ябырылган яулар, монгол-татарлар тарафыннан күп кенә илләрнең һәм халыкларның буйсындырылуы нәтиҗәсендә бик күп кешеләр – яугирләр һәм тыныч тормышлы халык кырыла, исән калганнар газапларга дучар ителә. Күп кенә шәһәрләр (Урта Азия, Кавказ һәм Көнчыгыш Европадагы кайбер шәһәрләрне генә искә алам, ягъни: Отрар, Бохара, Сәмәрканд, хәрәземшаһлар дәүләте башкаласы Үргәнеч, Шамхор, Дәрбәнд, Самцхе, Эрзурум, Идел-Чулман Болгарстаны башкаласы Биләр, Болгар, Суар, Җүкәтау, Рязань, Киев, Люблин, Краков, Загреб һ.б.), кирмәннәр һәм торак пунктлар җимертелә һәм яндырыла. Әмма, кытай ораторы Лу Цзя (б.э.к. III–II гасырлар), шулай ук Чыңгыз ханның киңәшчесе Елюй Чуцай (1189–1243) сүзләре белән әйткәндә, «атка атланып империя яулап булса да, ат өстендә генә утырып идарә итү мөмкин түгел». Көч кулланып кына империяләр озак яши алмыйлар, тиз таркалалар. Алтын Урда яшәешенең фәкать корал көченә, буйсындырылганнарның каршылыгын һәм ризасызлыгын рәхимсез рәвештә бастыруга, аларның яулардан соң көчсезләнүенә, җәза чараларының кабатлануыннан һәм һәлакәткә дучар булу ихтималыннан куркуларына нигезләнүе шикле (хәер, Алтын Урданың монгол-татарлардан мирас ителгән хәрби куәте чыннан да гаять зур була, гомуми алганда, гаскәрләрдә 250 мең яугир туплана алып, мистик дәрәҗәдә курку сеңдерә, буйсынмаучыларга карата чаралар яшен тизлегендә диярлек һәм котылгысыз хәлдә гамәлгә ашырыла). Кагыйдә буларак, яулау һәм буйсындыруга караганда, империяләрнең барлыкка килү һәм яшәеш процессы күпкә катлаулырак. Алар берләшү, ягъни билгеле бер үзара ризалык җирлегендә мәҗбүриләү һәм тормыш рәхәтлекләре кушылмасы нигезендә төзеләләр. Җәмгыять өчен файдалы, тәртип, икътисад, мәдәният үсеше һәм башкалар өчен гарант булган очракта гына империячел дәүләт тотрыклылана. Алтын Урданың оешуы да, аерым алганда, Үзәк Евразиядә һәм Көнчыгыш Европада күпкә ныклырак һәм тотрыклырак сәяси вазгыять урнашуга китерә. Яуланып, башта Монгол империясе, аннары Җүчи Олысы составына кергән халыклар һәм дәүләтләрнең күпчелеге элек даими кабатланган үзара низаглар һәм ызгышлар, эчке һәм тышкы бәрелешләр шартларында яшиләр. Алар арасында еш кына канкойгыч сугышлар кабына, шул сугышлар вакытында шәһәрләр җимерелә, торулыклар бушап кала. Җүчиләр империясе составына кертелү элекке тотрыксызлыктан һәм таркаулыктан кискен аермалы чагыштырмача ныклы дәүләт тәртибе урнашуын тәэмин итә. Сугышлар, үзара низаглар һәм эчке каршылыклар нәтиҗәсендә көчсезләнгән күршеләре арасында Алтын Урда чыннан да гаҗәеп «тотрыклылык утравы» буларак танылa.

Монгол-татарлар үзәкләшкән хакимият идеясен алып киләләр, Дәште Кыпчакның аңарчы зәгыйфь дәрәҗәдә оешкан дала кабиләләрен берләштерәләр. Көнбатыштагы яулардан җиңеп кайткан Бату, хәзерге Татарстан территориясендәге Биләр шәһәрендә, иярдән тәхеткә күчеп утырып, гаскәр башлыгыннан дәүләт төзүчегә әверелә. Ул һәм Җүчи Олысының аннан соңгы идарәчеләре ил белән идарә итүнең төзек, катлаулы тармакланган,

әмма шактый тотрыклы системасын төзиләр. Элеккеге кыпчак «Кыргый даласы»нда хөкем сөргән кабиләара низагларга һәм дошманлыкка алмашка халык төгәл унлыкларга бүленгән олыслардан гыйбарәт төзек һәм ныклы дәүләт системасы килә. Алай гына да түгел, төбәктә чын социаль революция гамәлгә ашырыла, ягъни ыруг-кабилә мөнәсәбәтләрен шартлы (сөйургал) һәм шартлар белән чикләнмәгән (тархан) ярлыкаш мөнәсәбәтләренә нигезләнгән хәрби-феодаль тәртипләр (строй) алыштыра. Нәтиҗәле дәүләт механизмы төзелә. XIII гасырның икенче яртысыннан алдагы йөз ел дәвамында диярлек сугыш хәрәкәтләре, элеккеге кыпчак югары катлавының юк ителүе яки хакимияттән читләштерелүе аркасында туган буталчыклык урынын «куәтле дәүләттә чагыштырмача тыныч, тотрыклы тормыш били» [В.В.Трепавлов]. XIV гасырның икенче яртысына кадәр Алтын Урданың эчке өлкәләрендәге шәһәрләренең кирмән диварлары һәм башка ныгытмалары булмавы да илдә хөкем сөргән иминлек һәм куркынычсызлык дәрәҗәсен күрсәтә.

Элеккеге төрки кабиләләр берлекләре таркатыла һәм Җүчи Олысының хәрби-административ һәм клан структурасына кертелә, аларның аксөякләре өлешчә юк ителә, өлешчә яңа аристократия составына кушыла. Җүчиләр хөкүмәте, салымнар җыюны һәм хәрби мобилизацияне уңайлаштыру мәнфәгатьләрен күздә тотып, һәм халыкның үз ирке белән олыслар арасында күчешен тыеп, үзенчәлекле «крепостнойлык хокукы» урнаштыра. Элек төрле этносәяси берләшмәләргә таркалган кардәш төрки кабиләләр беренче тапкыр гомуми территориаль-сәяси пространствода туплана. Дәүләт чикләренең һәм кабиләара киртәләрнең юкка чыгуы, низагларның бетерелүе һәм сәяси бердәмлек аларның үзара якынаюына этәргеч бирә, таркау төрки кабиләләрнең бердәм халыклар булып оешуы өчен алшартлар тудырып, мөһим этник процессларга юл ача. Нәтиҗәдә, Алтын Урда Евразиянең хәзерге күп кенә төрки халыклары өчен «этник бишек»кә әверелә, чөнки аларның килеп чыгышы процесслары «әлеге дәүләтнең төрле провинцияләрендә яшәгән халыклар нигезендә бара» [В.В.Трепавлов].

«Татарлар» этнонимы белән аталган хәзерге субэтник бергәлекләрнең (Идел-Урал, Кырым, Себер татарлары һ.б.) килеп чыгышы да күп кенә очракларда нәкъ менә Җүчи Олысында башлангыч ала. Хәзерге вакытта ике милләткә (кырымтатар һәм татар) һәм ике этник төркемгә (буджак һәм Литва татарлары) карата кулланылучы әлеге атама нәкъ менә Алтын Урда чорында киң таныла. Үзәк Азиянең көнчыгышында яшәгән кабиләләрнең берсе (соңрак – кабиләләр берлеге) исеме буларак, ул татар-монгол яуларына кадәр бик күп еллар элек Шәрыкъта еш кына Үзәк Азия халыклары җыелмасын, шул исәптән монголларны (кытай язма чыганакларындагы «кара татарларны» атау өчен кулланыла. Шуңа күрә урта гасырлар чыганакларының күпчелегендә этник яктан чуар монгол гаскәрләре «монголлар» буларак түгел, «монгол-татарлар» (мәсәлән, урта гасырлардагы әрмән тарихчысы Киракос Гандзакеци «мугал-татарлар» атамасын куллана)) яки «татарлар» буларак искә алына. Алтын Урданың төрки халык-



*Крымда үзбәк мәчете*



*Болгар. Кече манара янындагы мавзолей. Җүчи Олысы. XIV гасыр. Р.Ф. Шарифуллин фотосы*

лары исә, тарихта мәгълүм традиция буенча илбасар халык исемен кабул итеп, шул ук вакытта үзләренең кабилә атамаларын да кулланып, үзләрен «татарлар» дип атый башлыйлар. XV гасырда яшәгән гарәп филологы һәм тарихчысы Ибне Гарәбшаһның Җүчи Олысы хакында «бу – фәкать татарлар өлкәсе» дип язуы очраклы күренеш түгел.

Шулай итеп, Алтын Урда дәверендә бер үк вакытта этноним, политоним, соционим сыйфатында кулланылган «татарлар» төшенчәсе беренче тапкыр этник җәһәттә туплау мәгънәсенә ия булган. Дәүләтнең төп үзәге булган көнбатыш өлешендә (аны еш кына «Ак Урда» дип атыйлар) төркиләрнең бердәм татар бергәлегенә берләшүе башланган. Җүчи Олысы таркалуы аркасында бердәм татар халкы формалашу тукталып торган. Соңрак Әстерхан, Казан, Касыйм, Кырым һәм Себер ханлыкларында, өлешчә Нугай Урдасында, хәзерге Румыния, Польша, Литва һәм Белоруссия территориясендә аның нигезендә үзләренең этник бөтенлеген яхшы аңлаган локаль татар этник бергәлекләре (Әстерхан, Казан, Касыйм, Кырым, Себер татарлары, татар-мишәрләр, Добруджа һәм Польша-Литва татарлары һ.б.) оеша башлый. Төрле төбәкләрдәге татарларның этник тарихы процесслары Россия һәм башка дәүләтләр кысаларында дәвам итә.

Шул ук вакытта «Алтын Урданыкы» һәм «татарныкы» төшенчәләре арасында абсолют тиңдәшлек билгесе кую, минемчә, бик үк дөрес түгел. Хәзерге татар һәм кырымтатар милләтләреннән тыш, Россиядә һәм совет дәвереннән соңгы чордагы киңлекләрдә яшәүче төрки халыкларның күпчелеген Алтын Урданың этносәяси варислары дип исәпләү зарур, чөнки аларның килеп чыгышы һәм милли дәүләтчелек тамырлары шул дәүләткә барып тоташа. Балкарлар, башкортлар, казахлар, каракалпаклар, карачайлар, кумыклар, нугайлар, үзбәкләрнең бер өлеше һәм башка халыклар – Алтын Урда татарларының турыдан-туры варислары. 2011 елда казах галиме Жаксылык Сабитов хаклы рәвештә: «Алтын Урда татарлары хәзерге татарларның барлык төркемнәре (Казан, Себер, Әстерхан, Кырым, Польша-Литва татарлары), нугайлар, башкортлар, казахлар, каракалпаклар, Шәйбани белән бергә Урта Азиягә киткән үзбәкләр һәм



*Миниатюрада Үзбәк хан*



*Эски-Дюрбе мавзолее. Бахчасарай. В.С.Куколь*

башкалар өчен баба этнос булганнар», – дип язган иде. Минем шәхси фикерем: Алтын Урда – күп кенә төрки (һәм төрки булмаган) халыкларның, әмма тәүге нәүбәттә татарларның уртак тарихи казанышы һәм мирасы.

Гаять зур территорияләрнең Җүчиләр империясе составында берләшүе, алар арасындагы чикләрнең һәм таможня киртәләренең юкка чыгуы, уңай сәяси һәм этник нәтиҗәләргә китерү белән бергә, элеккегегә караганда күпкә киңрәк күләмдә чиксез зур матди ресурсларга үтеп керү һәм аларны ишәйтү мөмкинлеге биргән бердәм икътисади мәйдан оешуга алшартлар тудыра. Аерым алганда, Алтын Урдада үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы төрлелеге шартларында төрле табигый зоналарда (көньякта чүлләр һәм ярымчүлләр, төньякта далалар һәм урман-далалар, киң яфраклы урманнар, Себер тайгасы, шулай ук Кырымда һәм Кавказда субтропиклар) яшәгән һәм төрле хуҗалык-мәдәният типларына караган күпсанлы кешеләр төркемнәренең бер үк социаль-сәяси система кысаларында берләшүе аеруча зур әһәмияткә ия була. Алтын Урда территориясенең төп өлешен, үзәген далалар тәшкил итә; далаларда яшәгән халык элеккечә үк күчмә һәм ярымкүчмә тормыш алып бара, җәйләрдә көньяктан төньякка, кышларда киресенчә юнәлештә күченеп гомер кичерә. Урдада мал-туарның бик күп булуы сәяхәтчеләрне таң калдыра: итальян Йосафат Барбаро офыккача сузылган далаларда көтүләрнең өзлексез күченүен алты көн буе күзәтә. Шул ук вакытта Алтын Урданың үзәктән читтәге территорияләрендә һәм аңа бәйле җирләрдә (Харәзем, Төньяк Кавказ, Кырым Идел-Чулман Болгарстаны һәм рус кенәзлекләре) традицион рәвештә хуҗалык нигезен утрак игенчелек, бакчачылык һәм аранлы-көтүле терлекчелек тәшкил итә. Халыкның хуҗалык шөгыльләре арасында чолыкчылык, балыкчылык һәм сунарчылык зур роль уйный. Нәтиҗәдә Алтын Урда икътисады күп укладлы рәвеш ала һәм, ахыр чиктә, болар барысы да территорияләр арасында, бигрәк тә дәүләтнең үзәк төбәге булган Идел буенда, Оксфорд университеты хезмәткәре Мари Фаверо Думенжу билгеләп үткәнчә, «үзара алыш-бирешнең аңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә интенсивлашуына китерә». Җү-

чи Олысы хакимлегендәге җирләрдә глобаль дәрәҗәдә гомуми акча әйләнеше системасын булдыру икътисади киңлекнең бердәмлеген саклауда һәм ныгытуда гаять зур әһәмияткә ия була, чөнки Урда составына кертелгән күп кенә территорияләрнең үзләрендә элек алга киткән акча сугу традицияләре күзәтелми. Илнең төбәкләрдәге акча сугу үзәкләреннән торган акча системасы торган саен ныграк бердәйләштерелә бара. Берничә акча реформасы барышында ул тәртипкә салына, бердәм авырлык нормасы буенча сугылган алтын динарларны, көмеш дирһәмнәрне һәм бакыр пулларны үз эченә алган бердәм төзек структура хәленә китерелә.

Эчке товар алмашу үсешеннән бигрәк, халыкара сәүдә үсешендә Алтын Урда тагын да мөһимрәк роль уйный. Географик яктан гаҗәеп уңайлы урын биләве аркасында ул трансконтиненталь кәрван юллары кисешкән үзәккә әверелә. Атаклы Бөек ефәк юлының төньяк тармагы әлеге юлларның иң әһәмиятлесе була, ул Кытайда башланып, Көнчыгыш Төркестан, Җидесу өлкәсе, Харәзем аша Идел буена, аннан Үзәк Европага сузыла. Урта һәм Якын Көнчыгышта барган сугышлар, хөкем сөргән тотрыксызлык шартларында отышлы билгеләнгән конъюнктура нәтиҗәсендә Кытайдан килгән товарлар ташкыны (аш тәмләткечләр, мамык, асылташлар, икмәк һәм коллар) Европага нәкъ менә тынычрак вазгыятьле Алтын Урда аша агыла. Мөселман Шәрыгын Төньяк-Көнчыгыш һәм Төньяк Европа, Балтыйк буе белән бәйләгән Идел буе «Мех юлы» (төньяктан көньякка таба юнәлештә) да әһәмиятлеге ягыннан калышмый. Шулай ук Кара диңгез – Идел (Кара диңгез буен Түбән Идел буе белән бәйләп, Урта Азия аша Кытайга һәм Һиндстанга сузылган) һәм транскавказ (Якын Көнчыгыш Көньяк-Көнчыгыш Европа белән бәйләнгән) юллары да Алтын Урдада башлангыч ала.

Алтын Урданың хуҗалык тормышында Европа һәм Азия илләре белән этрафлы товар алмашу әһәмиятен бәяләп бетерү кыен. Әлеге багланышлар хан казнасын тулыландыра, төрле арадашчыларны һәм күпсанлы хезмәтчеләрне баета. Моннан тыш, транзит сәүдә белән беррәттән, Алтын Урда хакимлегендәге территорияләрдән күпләп читкә ашлык, мехлар, күн товарлар, коллар чыгарыла. Экспортның төп өлешен Көнбатыш Европаның тышкы базарларында, шулай ук Идел буенда үрчетелгән токымлы аргамаклар югары бәяләнгән Якын һәм Урта Көнчыгышта ихтыяҗ гаять зур булган төрле мал-туар тәшкил итә. Алтын Урдага күп кенә төрле зиннәтле әйберләр, кыйммәтле корал, тукымалар, аш тәмләткечләр һәм башка товарлар кертелә, беренче чиратта алар хан сарае һәм аксөякләр тарафыннан кулланыла. Югарыда күрсәтелгәннәр сәбәпле, элек Чыңгыз хан гамәлгә керткән традицияләр буенча Алтын Урдада сәүдәгәрләргә үзенә бер аерым химаячелек күрсәтелә. Сәүдә үсешен кызыксындыру өчен дәүләт таможня җыемнарын товар бәяләренең өч–биш процентыннан артмаган түбән дәрәҗәдә тотарга тырыша. Империядә урнаштырылган тәртипләр сәүдәгәрләрнең тормышын, абруен һәм мөлкәтен саклауга юнәлтелә, көчле хакимият товарлы кәрваннар йөрешенең иминлеген тәэмин итә.

Алтын Урданың югары катлауларына трансконтиненталь сәүдә китергән әкәмәт зур файда һәм керемнәр мөһим дәрәҗәдә ханнарның һәм алар даирәсенең халыкара дәгъвалары үсүгә сәбәпче була, аларны тышкы экспансияне дәвам итүгә этәрә. Әһәмиятле сәүдә шәһәрләрен яулау һәм үз контролен Бөек ефәк юлының Балкандагы һәм Кече Азиядәге өлешләренә җәелдерү омтылышы Җүчи Олысының Һулагу Олысы – Илханнар дәүләтенең (Урда аның белән 1260–1390 нчы елларда хәзерге Әзербайҗан территориясендә, үзгәрүле уңышларга ирешеп, сугышлар алып бара), Византиянең һәм тәре йөртүчеләрнең гарәпләр җирләрендәге корольлекләренең стратегик дошманына, шул ук вакытта мәмлүкләр Мисырының һәм Кече Азиядәге сәлҗүк төрекләренең союздашына әверелүенә китерә. XIII гасыр уртасыннан XIV гасыр ахырынача идарә иткән мәмлүк солтаннарының чыгышы кыпчак тамырларына тоташуы һәм мөселман хәлифәлегенең үзәге Багдадтан Мисырга күчерелүе нәтиҗәсендә Урда – Мисыр багланышлары аеруча ныгый бара. Гомумән, Алтын Урданың тышкы сәясәте һәм элемтәләре киң колачлы булуы белән аерылып тора, багланышларның интенсивлыгы аның дөнья белән тыгыз бәйләнештә булуын күрсәтә. Халыкара мәйданда Җүчиләрнең абруе гаҗәп югары була. Җүчи Олысы халыкара сәяси мәйданда мөһим уенчыга әверелә, аның идарәчеләре исә, Үзәк Евразиядә яңа, тәкъдир хөкемдарлары ролен үзләштереп, якын һәм ерак илләрдәге – Кытайдагы, Һиндстан, Әрмәнстан, Урта Азия, Русь, Литва, Польшадагы, Балкан һәм Апеннин ярымутрауларындагы сәяси вакыйгаларга актив йогынты ясый башлыйлар. Киң тармакланган союзлар системасы аркылы Алтын Урданың йогынтысы, турыдан-туры булмаса да, «Тевтон ордены җирләренә һәм хәтта Испаниягә кадәр җәелә» [Bertold Spuler]. Мари Фаверо хаклы рәвештә: «Алтын Урда XIII гасыр уртасында – XIV гасыр уртасында барган сәүдә экспансиясенә зур йогынты ясый, аның икътисади һәм сәяси идарәсе югары дәрәҗәдә Иске Дөньяның глобальләшүенә булышлык итә... Чыңгызыйларның яулап алулары тәгәлләнгәч, сәүдә шаукымы кешелек җәмгыятен һәм Евразиянең мәдәни ландшафтын үзгәртеп кора... Алтын Урда әлеге драматик алмашуның сәхнәсе була. Җүчиләр дәүләте ханнары һәм бәкләре яңа халыкара тәртиптә әйдәүче роль уйныйлар», – дип ассызыклый.

Нәкъ менә сәүдә, беренче чиратта тышкы сәүдә, Алтын Урда белән бәйле тагын бер күренекле тарихи феноменга – аның күчмә халыклар иленнән шәһәрләр иленә әверелүенә сәбәпче фактор була.

5

Шәһәр халкының географиясе сәүдәнең Алтын Урданың күчмәннәр иленнән шәһәрләр иленә әверелү процессындагы ролен аермачык күрсәтә – шәһәр халкы нәкъ менә төньяктан көньякка һәм көнбатыштан көнчыгышка юнәлгән кәрван юллары кисешкән җирләрдә, шул юллар буйлап аеруча тыгыз урнашкан. Урта гасырларга караган язма тарихи чыганаклардагы хәбәрләр һәм карталар буенча, шулай ук археологик тикшеренүләр нәтиҗәсендә Алтын Урда территориясендә 150 ләп шәһәр бу-

луы мәгълүм [В.В.Бартольд, Г.А.Федоров-Давыдов, В.Л.Егоров һ.б. хезмәтләрен кара]. Иң эре шәһәрләр исәбенә Болгар (хәзерге Татарстан) һәм Мухша/Наручат (Пенза өлкәсе), Сарай әл-Мәхруса һәм Хаҗитархан (Әстерхан өлкәсе), Сарай әл-Җәдид һәм Билҗәмин (Волгоград өлкәсе), Кырык Ир һәм Кырым/Солхат (Кырым), Үкәк (Саратов өлкәсе), Азак (Ростов өлкәсе), Маҗар (Ставрополь крае), Дәрбәнд (Дагстан), Сарайчык һәм Сыгнак (Казахстан), Үргәнеч (Үзбәкстан), Аккирмән (Украина) һ.б. кергән. Әлеге исемлектә татар-монгол яулары вакытында яндырылган һәм таланган, таркалу хәленә килгән һәм бушап калган, халкы өлешчә кырып бетерелгән, өлешчә әсирлеккә алынган һәм коллыкка алып кителгән, әмма тиз арада торгызылып, Алтын Урда чорында да яшәүләрен дәвам иткән элеккеге шәһәрләр дә, актив рәвештә илнең төрле өлешләрендә калкып чыккан шәһәрләр дә очрый. [Алтын Урданың Болгар олысы шәһәрләре, аерым алганда, Казанның үсеше хакында Р.Г.Фәхретдинов, Ю.А.Зеленеев, К.А.Руденко, А.Г.Ситдыйков һ.б. хезмәтләрен кара]. Сәүдәдән тыш, шәһәрләрнең барлыкка килүе һәм үсеше буйсындырылган территорияләрне идарә итү өчен терәк пунктлар челтәре булдыру зарурлыгы белән дә бәйле була. Шуңа күрә Алтын Урданың күп кенә шәһәрләре эре административ-территориаль берәмлекләр үзәкләре вазифаларын да башкарганнар. Өстәвенә, ханнар һәм аксөякләрнең югары катлавы, кышлау өчен генә шәһәрләргә барып, вакытларының күп өлешен үзләренең күчмә станнарында уздыруны өстен күрсәләр дә, күпсанлы профессиональ чиновникларның бюрократик аппараты өчен стационар яшәү урыны таләп ителгән. Бәйле җирләрдән кергән бай ресурсларны һәм гаять зур керемнәрне үз кулларында туплаган, дәрәҗәле саналган күчмә тормыш рәвешен саклаган аксөякләрдә дә тора-бара шәһәрләрдәге зиннәтле утрак тормыш уңайлыкларына һәм рәхәтлекләренә омтылыш үсә барган. Алтын Урда хөкемдарларының Бату тарафыннан ук башланып алып барылган һәм XIV гасырның беренче яртысында Үзбәк һәм аның улы Җанибәк ханнар заманында аеруча киң колач җәйгән актив һәм максатчыл юнәлешле шәһәрләр төзү сәясәте нәкъ менә шул факторлар һәм сәбәпләр белән аңлатыла.

Яңа корылучы шәһәрләрнең беренче төзүчеләре һәм эшчеләре яуланган җирләрдән куып китерелгән тоткыннар була. XIII гасыр уртасында Монгол империясендә булып киткән Плано Карпини монгло-татарлар «иң яхшы һөнәрчеләрне алып китәләр һәм аларны үзләренең барлык эшләрен башкаруга куялар», дип яза. Әмма XIV гасырның беренче яртысында ук, Җүчи Олысы Үзбәк һәм Җанибәк заманнарында үзенең чәчәк ату чорына аяк баскач, буйсындырылган, күрше һәм ерак илләрдән югары квалификацияле осталар үзләренең һөнәри тәҗрибәләре, хезмәте һәм эшләнмәләре югары бәяләнгән, аларга ихтыяҗ һәм түләү тотрыклы һәм югары булган Алтын Урда шәһәрләренә бик теләп күченеп урнаша башлыйлар. Шуның нәтиҗәсе буларак, илдә металл эшкәртү, пыяла эшләү, чүлмәкчелек, зәркәнчелек, сөяктән әйберләр эшләү һөнәрләре, төзелеш плитәләре һәм керамика җитештерү, шулай ук башка тармаклар тиз темплар белән үсә.

Архитектура һәм төзелеш эше югары үсеш дәрәҗәсенә ирешә [Э.Д.Зиливинская хезмәтләрен кара] – ак таштан һәм кирпечтән (яндырылган һәм яндырылмаган кирпечтән) капиталь сарайлар һәм җәмәгать биналары (мәчетләр, мунчалар, кәрвансарайлар, дөрбәләр һ.б.) төзелә, аларның диварлары бизәкле штукатурка, сырлы ганч һәм төрле төсләрдәге ялтыравык йөгертелгән чынаяк кирпечләр белән тышлана. Идән астыннан уздырылган җылыту системалары югары дәрәҗәдә төзеклек һәм уңайлык тәэмин итә.

Шәһәрләр тыгыз утар-квартал планировкасы буенча төзелә. Ярымутрак яисә тулысынча утрак тормышка күчкән аксөяк күчмәннәр массачыл рәвештә шәһәр чикләре эчендә һәм шәһәр бистәләрендә биек диварлар белән камалган күп бүлмәле хуҗа йортын, хезмәтчеләр торакларын һәм хуҗалык корылмаларын, кайбер очракларда фонтаннар куелган һәм бакчалар урнаштырылган сулыкларны үз эченә алган зур (ярты гектарга кадәр мәйданда) утарлар коралар. Гади халык тирмәләрдә, землянкаларда, агач һәм балчык диварлы бер бүлмәле йортларда яши. Билгеле бер төрле җитештерү белән бәйле һөнәрчеләр, әрмәннәр, яһүдләр, греклар, итальяннар һәм руслар колонияләре аерым кварталлар хасил итә.

Алтын Урданың дәвамлы тарихи үсеш мирасы буларак барлыкка килгән шәһәрләре дә, ханнар әмере буенча гаҗәеп тиз арада төзелгәннәре дә берничә дистә ел эчендә үзләренең мәһабәтлеге, зурлыгы һәм төзеклеге белән күрелмәгән үсеш дәрәҗәсенә ирешәләр. Күп кенә халыкларның шәһәрләр төзү традицияләрен үзләштереп, үзләренә сеңдереп, алар тиңдәшсез сыйфатларга һәм үзенчәлекләргә ия булалар, кабатланмас манзаралары белән таң калдыралар. Алтын Урданың төзек, су белән тәэмин ителгән, уңайлы һәм матур биналар, мәчетләр һәм төз, биек манаралар калкып торган, мунчалар һәм каналлар, бакчалар һәм сарайлар тезелеп киткән шәһәрләренең көнкүреше, аерым алганда, Дәүләт Эрмитажы директоры, күренекле шәркыятьче галим Михаил Пиотровский билгеләп үткәнчә, шул заманның югары стандартларына һәм таләпләренә туры килгән. Бу хакта сакланып калган яки археологлар тарафыннан табылган предметлар, шәһәрләрдәге интенсив, бай һәм имин тормышны шаккатып тамаша кылган чит ил сәяхәтчеләренең сокланулы хатирәләре шаһитлек итә. Җүчи Олысының 1240 елларда Бату тарафыннан нигезләнгән икенче (Болгардан соң) башкаласы Сарай әл-Мәхруса кунакларны үзенең мәһабәтлеге һәм зурлыгы белән хәйран калдыра. Урта гасырлар үлчәмнәре буенча ул, хәзергечә әйтсәк, шул дәвердәге Багдад һәм Каһирә, Константинополь һәм Рим белән чагыштырырлык чын мегаполис була: аның мәйданы (бистәләре белән бергә) 36 кв. километрга, халкы исәбе (замандашлары бәяләвенчә) 75 мең кешегә җитә. XIV гасырның беренче утызъеллыгында башкала Үзбәк хан идарәсе вакытында төзелгән Сарай әл-Җәдидкә күчерелә. Әлеге шәһәр Үзбәк ханның улы Җанибәк хан заманында чәчәк ату чоры кичерә, соңгысы хан сараен (даирәсен) шунда күчерә.

Бер мөһим моментны аерым билгеләп узыйм. Тарих фәнендә традицион рәвештә Сарай әл-Мәхруса – Россиянең Әстерхан өлкәсендәге Селитрён-



*Кульязмалар өчен футляр (Филактерий). Көмеш. Гравировка. Җүчи Олысы XIV–XV гасыр башы*



*Лотос формасында аел. Алтын йөгертелгән көмеш. Җүчи Олысы. XIV гасыр. Эрмитаж*

ное шәһәрлеге, Сара әл-Җәдид исә Волгоград өлкәсендәге Царёво шәһәрлеге белән тиңләштерелә. Әмма яңа фаразлар буенча, алар башка урында урнашканнар яисә, гомумән, бер үк шәһәр төрлечә аталган. Шул ук вакытта, мәсәлән, Фра Мауроның дөнья картасында (1459 ел) ике шәһәр күрсәтелеп, берсе – «Сарай», икенчесе – «Сарай Грандо» атамалары белән билгеләнгән.

Абруйлы тикшеренүче-белгечләр фикренчә, Җүчи Олысында шәһәрләшү нәтиҗәсендә «дәүләтнең аерым төбәкләре эшкәртелгән кыр-басулар белән әйләндереп алынган кечерәк шәһәрчекләрдән, бистәләрдән һәм аксөяк замокларыннан торган, күп чакрымнарга сузылган тулаем утрак торулыкларга әверелә» [В.Л.Егоров]. Алтын Урданың үзәк төбәгендә – уңайлы табигать шартлары (уңдырышлы тугай-үзәнлекләр, даладагы терлекчелек мәйданнары, суднолар йөргән һәм төп кәрван юллары кисешкән Түбән Идел буенда Сарай әл-Мәхрусадан Сарай әл-Җәдидкәчә өзлексез сузылган гаять зур шәһәр агломерациясе барлыкка килә.

Әлеге өлкәдә, ике Сарайдан тыш, башка шәһәрләр дә – Хаҗитархан, Билҗәмин, Үкән, Гөлстан һәм Сарайчык урнашкан, алар үзләрен камаган дистәләрчә торулыклар белән бергә халык тыгыз утырган игенчелек оазисын хасил иткәннәр. Идел белән Дон елгалары арасында да шундый ук агломерация яшәп килгән.

Корылыклы төбәкләрдә сугару һәм күпсанлы шәһәр халкы өчен үсемлекчелек-игенчелек продукциясе (азык-төлек, техник культуралар) җитештерү мәсьәләләрен хәл итү белән бәйле рәвештә бер үк вакытта әйләнә-тирә мохитне үзгәртеп корудан башка әлеге гигант урбанистик организмнар барлыкка килә һәм яши алмас иде. Шәһәрләрне су белән тәэмин итү мәсьәләсе ясалма күлләр-сусаклагычлардан һәм катлаулы гидротехник корылмалардан (буалар, шлюзлар, дамбалар, арыклар, җир астындагы керамик торбалардан корылган сүүткәргечләр һәм канализация) гыйбарәт күптармаклы система булдыру юлы белән хәл ителгән. Икенче мәсьәләне чишү өчен «чирәм җирләрне күтәрергә» – игенчелек максатында даланы массачыл колонияләштерергә һәм шәһәрләрне авыл хуҗалыгы торулыклары белән әйләндереп алырга туры килгән. Моның ни рәвешле гамәлгә ашырылуы әлегә җентекләп



*Полуфаянс чаша. Җүчи Олысы. XIV гасыр*



*Персид язулы тондо. Кашин, полихром мозаика. Җүчи Олысы. XIV гасыр*

һәм ахыргача өйрәнелмәгән, әмма проектның колачлары гына да Алтын Урда дәүләтенең югары оештыру потенциалын күрсәтә.

Шулай итеп, Алтын Урда империясе яшәеше чорында һәм нәтиҗәсендә, мөгаен, тарихта аңарчы күрелмәгән-күзәтелмәгән цивилизацион үсеш-үзгәреш булган – халкының күпчелеге күчмә халыклардан торган ил нибары берничә дистә ел дәвамында шәһәр һәм күчмәнлек-игенчелек мәдәниятләрен берләштергән югары дәрәҗәдәге үсешле «оазис»ка әверелгән. «Аерым шәһәрләр генә түгел, күчмәннәр һәм утраклык мәдәниятләрне берләштергән күренекле цивилизация үзәгенә әверелгән тулы бер игенчелек өлкәсе» буш диярлек урында барлыкка килгән [Д.М.Исхаков, И.Л.Измайлов]. Идел буе археологик экспедициясен нигезләүчеләрнең берсе һәм аның җитәкчесе, Мәскәү дәүләт университеты профессоры, атаклы совет һәм Россия тарихчысы археологы Герман Фёдоров-Давыдов (1931–2000) кыска вакыт эчендә далада күп кенә шәһәрләр үсеп чыгуның урта гасырлар тарихында уникаль күренеш булуын күп тапкырлар ассызыклады.

Алтын Урда тарихында шәһәрләрнең аеруча зур роль уйнавы, сәүдә-һөнәрчелек һәм сәяси тормыш үзәкләре булу белән бергә, аларның интеллектуаль-рухи тормыш, Алтын Урда мәдәнияте формалашуы һәм үсеше үзәкләренә әверелүеннән дә гыйбарәт.

Күчмә халыкларның тиз хәрәкәт итүгә сәләтле булулары сәбәпле, күпсанлы күршеләре белән еш очрашулары нәтиҗәсендә аларның мәдәнияте һәрвакыт ныграк баеган. Монгол-татар яулары һәм Җүчи Олысының барлыкка килүе тагын да киңрәк колачлы мәдәни-тарихи процессларны хәрәкәткә китергән. Империя буларак, Алтын Урда төрле мәдәниятләр вәкилләре яшәгән төбәкләрне бердәм сәяси яссылыкта туплаган, бу исә, үзара социаль-сәяси тәҗрибә уртаклашудан һәм сәүдә-хуҗалык элементләре ныгудан тыш, интенсив мәдәниятара багланышлар үсеше өчен җирлек хасил иткән. Евразиядәге күпсанлы халыкларның һәм кабиләләрнең мәдәни традицияләрен үзенә сеңдереп, Алтын Урда көчле үзенчәлекле феноменга әверелгән яңа мәдәният тудырган!

Әлеге мәдәният XIII гасырның

икенче яртысыннан, башлыча Көнчыгыш Европадагы җирле (иң элек болгар һәм кыпчак) һәм читтән килгән Үзәк Азия (әүвәл нәүбәттә татар-уйгыр һәм кидан-чжурчжэн) традицияләре кушылуы нигезендә формалашкан. Үзәк Азиядән чыккан аз санлы килмешәкләр буйсындырылган халыкларның мәдәниятен кабул иткәннәр, бер үк вакытта аңа үзләренең Евразия мирасыннан да күп кенә үзенчәлекләр, шулай ук Шәрыкъның борынгы цивилизацияләре (мәсәлән, Кытай һәм Персия) йогынтысын да керткәннәр.

Мәдәниятләрнең үзара кушылуы, тәэсир итешүе һәм баетылуы Алтын Урда нәфис сәнгате мисалында ачык күренә. Аның үсешенең элгәреге чоры (XIII гасырның икенче яртысы) өчен стиленә Ерак Көнчыгыш һәм Үзәк Азия традицияләренең үтеп керүе, аларның җирле мотивлар белән үрелүе хас. Аның стиль синкретиклыгына (бөтенлегенә) ирешүенә далакүчмәнлек һәм күчмәнлек-игенчелек, тәгаен утраклык һәм шәһәр традицияләренең симбиозы, ягъни янәшә чиратлашуы булышлык итә. Әлеге сәнгать шулай ук Шәрыкъ һәм Европа колориты белән сугарыла: «зәркәнчелек эшендә, нәфис һөнәрләрдә, керамикада, архитектурада сизелерлек рәвештә Кытай, Монгол, Иран, Якын Көнчыгыш, Европа тәшкил өлешләре чагыла» [М.Б. Пиотровский]. Соңрак – XIII–XIV гасырлар чигендә аңа XIV гасырның беренче чирегендә Үзбәк хан чорында Алтын Урданың рәсми диненә әверелгән исламның һәм мөселман илләре сәнгатенең йогынтысы көчәя башлый. Ислам үз төсмерен һәм үзенчәлекләрен өсти: сәнгать стилистикасы сурәтләүне каллиграфия һәм орнамент яссылыгына кайтарып калдыруга омтылган мөселман кануннары билгеләгән тәртипләр кысаларына кертелә. Шулай да халык көнкүреш иҗатында исламга кадәрге традицияләрдән килгән образларны куллану күпкә озаграк дәвам итә. Барлыкка килгән яңа сәнгатьтә «төрки сәнгати традицияләр... Монголия, Кытай, Россия һәм Көнчыгыш Европа сәнгати ысуллары белән диалогка керә», бу исә «Алтын Урданың барлык дөнья белән тере матди һәм рухи элемтәләрен чагылдыра» [М.Б.Пиотровский].

Нәфис сәнгать иҗаты башлыча декоратив-гамәли жанрда үсеш кичерә (асылда урта гасырлар сәнгатенә хас күренеш). Бизәмәләр, кием детальләре, савыт-саба, көнкүреш һәм культ (дини) әйберләре, кораллар, яугир һәм ат кирәк-яраклары – болар барысы да затлы металлар, асылташлар һәм ярым асылташлар белән, үсемлек рәвешендәге, геометрик, зоо- һәм антропоморфик, гарәп язулы сурәтләр һәм бизәкләр чүкеп, уеп, аларны төрле төсләргә кертеп бизәлә. Алтын Урда осталары иҗат иткән күп кенә эшләнмәләр гаҗәеп сәнгать үрнәкләре буларак бәяләнәләр һәм бүгенге көндә дә Россиядә (аерым алганда, Санкт-Петербургтагы Дәүләт Эрмитажында) һәм чит илләрдә дөньяның атаклы музейлары экспозицияләрендә һәм фондларында лаеклы урынnарын билиләр.

Алтын Урдада актив шәһәр төзелеше процессы тагын бер сәнгать жанры – монументаль-декоратив сәнгать һәм аның мозаикалы, майоликалы һәм уеп ясалган терракота тышлык-капламнар, фрескалы бизәкләр, ташны һәм гипсны бизәкләп сырлау,

гипс коелма һәм пластика рәвешендәге үрнәкләре үсеше өчен җирлек тудыра. Төрле төсләрдәге һәм орнаментлы бай бизәкләр урын алган, алтын йөгертүле декоратив майолика югары дәрәҗәдәге үсешкә ирешә, ул биналарның фасадларын һәм интерьерларын, кабер ташларын тышлауда, бизәүдә кулланыла. Болгар, Солхат, Кырык Ир (Чуфут-Кала), Иске Йорт (Бакчасарай), Үргәнеч һәм башка шәһәрләрнең сакланып калган архитектура истәлекләренең конструкция-декоратив детальләрендә, орнамент композициясендә, буяуларның төсләр төрлелегендә Урта Азиядәге мөселман илләре, сәлҗуклар Кече Азиясе, мәмлүкләр Мисыры, Һулагулар Ираны архитектурасы йогынтысы чагыла.

Югарыда әйтелгәнчә, Алтын Урда сәнгате күп кенә халыклар традицияләрен үзенә сеңдерә, тикшеренүчеләр хаклы рәвештә аның синкретик характерда булуын билгеләп узалар. Әмма Алтын Урда сәнгатенең фәкать читтән үзләштерелгән асылы хакында сүз йөртү тамырдан ук дөрес булмас иде, чөнки уникаль булуы сәбәпле, «Алтын Урда сәнгате әсәрләре җитәрлек дәрәҗәдә ачык чагылышлы, тәэсирле һәм алар танылa, мәгълүм», бу исә традицияләрнең гадәти гомумиләштерелүен (синтезлануын) генә түгел, аның нигезендә «билгеле бер, күп яктан бердәм стиль» эшләнүен күрсәтә [Э.Д.Зивилинская]. Заманында Герман Фёдоров-Давыдов төгәл ассызыклаганча, «эклектик рәвештә бергә кушылган элементларның күптөрлелеге гамәли сәнгатьтә – Алтын Урда мәдәниятенең төп сәнгатендә яңа стильнең, мөһим дәрәҗәдә «патетик» (тәэсирле. – Б.Х.) «рәсемлелек»кә көчле юнәлеш тоткан стильнең көчле яңгырашы белән каплана». Нәтиҗәдә, Алтын Урда осталарының югары сәнгать сыйфатындагы әсәрләре дәүләт чикләреннән еракларда киң танылa; мәсәлән, алар рус идарәчеләренең, чиркәү иерархларының сарайларында кулланышка керә [М.Г.Крамаровский]. Алай гына да түгел, сәнгать белгечләре фикеренчә, бигрәк тә металлны сәнгати эшкәртү һәм зәркәнчелек өлкәсендә, урта гасырларда алар күрше һәм ерак илләрдәге, аерым алганда, Көнбатыш Европадагы осталар иҗатына сизелерлек йогынты ясыйлар.

Алтын Урда барлыкка килүдән үсеп чыккан мәдәни алгарыш сынлы сәнгатьтә генә чагылып калмыйча, рухи, гуманитар мәдәният үсешенә дә көчле этәргеч бирелә. Бердәм дәүләт төзелү нәтиҗәсендә төрки халыкларның бердәм мәдәни-тел мәйданы, даирәсе оеша, ул лингвистик вазгыятьтә мөһим үзгәрешләргә китерә. Җирле угыз-кыпчак һәм болгар шивәләре җирлегендә шәһәрләрдә гомумхалык сөйләм койнесы, аның нигезендә исә гомумтөрки әдәби тел (XIV гасыр башы язма ядкаре – мәшһүр «Кодекс Куманикус»та («Коман мәҗмугасы»нда) «татар теле» дип атала) формалаша [А.Н.Гаркавец], ул, үз чиратында, иске татар теле һәм башка төрки әдәби телләр өчен нигез хасил итә. Башта – уйгур алфавитына, алга таба ислам таралуга бәйле рәвештә гарәп графикасына нигезләнгән бердәм язу куллануның гамәлгә керүе зур әһәмияткә ия була. Мәктәпләр һәм мәдрәсәләрнең (алар каршында китапханәләр, хаттат-каллиграфлар һәм китап күчерүчеләр мәктәпләре эшли) киң челтәре үсеш кичерә, нә-

тиҗәдә ил халкының югары һәм урта катлаулары уку-язуны камилрәк үзләштерү, исламның төп кануннарын тирәнрәк өйрәнү мөмкинлегенә ирешәләр. Язулы күп кенә көнкүреш әйберләре табылу, шулай ук күпсанлы кабер ташларындагы язмалар халыкның укый-яза белү сәләте шактый югары кимәлдә булуын күрсәтә.

Язу һәм әдәби тел булуы Алтын Урда югары мәдәниятенең тагын бер мөһим күрсәткече – күп жанрлы әдәбият үсеше өчен җирлек тудыра. Әлеге факт хәзерге заман тикшеренүчеләренең [Х.Й.Миңнегулов, Р.Н.Бохараев] хезмәтләрендә этрафлы яктыртыла. Кагыйдә буларак, урта гасырларда фикер ияләре, язучылар, дин эшлеклеләре фәкать хакимлекле затлар химаясе һәм хәйриясе шартларында гына иҗат итә, эшли алганнар, иганәчелек исә изге гамәл саналган. Алтын Урдада Бәркә, Үзбәк һәм Җанибәк ханнар фән һәм әдәбиятны үз канатлары астына алганнар: аларның сарайлары каршында мөселман Шәрыгының төрле илләреннән – Мисырдан, Сүриядән, Кече һәм Урта Азиядән килгән күп кенә күренекле галимнәр һәм язучылар яшәп иҗат иткәннәр. Урта гасырларда яшәгән гарәп тарихчысы Әхмәд ибне Гарәбшаһ сүзләренә караганда, кыска гына вакыт эчендә Каһирәдә дә күрелмәгән күләмдә «галимнәрне һәм атаклы затларны, тел белгечләрен һәм осталарны» җыеп, башкала Сарай «фән тупланган үзәккә әверелгән». Шул ук вакытта, чит илләрдән килгән затларның саллы өлеше һәм уңай йогынтысы хакында сүз йөрткәндә, Алтын Урда чоры әдәбиятының чәчәк атуында җирле зыялыларның мөһим роль уйнавын да искәрү зарур, бу хакта алар туган урынны чагылдырган нәсәп атамалары («-Болгари», «-Саксини», «-Суари», «-Сараи», «-Харәзми» һ.б.) шаһитлек итә. Урда укымышлылары башка мөселман илләренә дә барып чыкканнар.

Алтын Урда әдәбияты органик рәвештә тамырлары Әхмәд Йүгнәки, Йосыф Баласагуни, Әхмәд Ясәви, Сөләйман Бакыргани, Кол Гали, башка шагыйрьләр һәм язучылар иҗатлары белән бәйле элгәреге төрки (шул исәптән болгар) традицияләрне мөселман Шәрыгының гарәп-фарсы язма мәдәнияте (Фирдәүси, Газали, Низами, Гаттар, Руми, Сәгъди, Мәгари, Әбү Хәмид, Нәваи һ.б.) белән тоташтыра. Әсәрләрнең шактый өлеше күренекле гарәп һәм фарсы авторларының төрки телгә күчерелеп, «җирле фольклор һәм әдәби канунга кергән», төрки мәдәнияткә яраклаштырылган әсәрләрен компиляцияләү юлы (авторларның әсәрләреннән чүпләп әсәр төзү) белән тудырыла [Э.Г.Сәйфетдинова]. Җүчи Олысының күпчелек язма ядкарьләре төрки телдә языла; галимнәр шулай ук гарәп телен, шагыйрьләр фарсы телен киң кулланалар. Алтын Урданың язма ядкарьләре идея эчтәлегенең һәм сәнгать формаларының байлыгы, сөйләм стилистикасының нәзакәтлелеге, шигъри һәм прозаик жанрларның күптөрле булуы (кыйссалар, дастаннар, намәләр, нәсыйхәтләр, хикмәтләр, мәсәлләр, мөназәрәләр, хикәятләр, тәүхидләр, нәһетләр, мәдхияләр, мәрсияләр, касыйдәләр, газәлләр, мәснәвиләр, робагыйләр, фәрдләр һ.б.) [Ә.М.Шәрипов]. Кагыйдә буларак, урта гасырларга хас үзенчәлекләр аркасында дини һәм дөньяви, әдәби һәм фәннифәлсәфә әсәрләр арасында төгәл генә

чик уздыру кыен, аларда эстетик, танып-белү, этика-нәсыйхәт мәгънәләре бергә үрелә. Алтын Урда әдипләре, ягъни шагыйрьләре һәм язучылары сюжетларының төп мотивлары кеше яшәеше, яшәү мәгънәсе, Аллаһка мөнәсәбәт, җәмгыятьнең гадел төзелеше, идарәчеләрнең һәм аларның хакимиятендәгеләрнең үзара мөнәсәбәтләре, мәхәббәт, мораль-этика проблемалары өлкәләренең һәм башкаларның төрле мәгънәләреннән гыйбарәт була.

Һич тә арттырусыз әйтсәк, Алтын Урда язучыларының дини-нәсыйхәтле әсәрләре, аерым алганда, Борһанетдин Рабгузинең «Кыйссасел-әнбия»се («Пәйгамбәрләр тарихы», 1310), Әбүбәкер Каландәрнең «Каландәрнамә»се (1320–1340 нчы еллар), Мәхмүд Болгаринең «Нәһҗел-Фәрадис»е («Җәннәт юлы», 1358), Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан»ы (1369), билгесез авторның «Кисекбаш»ы, дөньяви эчтәлекле әсәрләрдән Харәзминең «Мәхәббәтнамә»се (1353), Котбның «Хөсрәү вә Ширин»е (1383), Сәйф Сараинең «Гөлестан бит-төрки»е һәм «Сөһәйл вә Гөлдерсен»е (1391), Әхмәд Хаҗи әс-Сараи, Мәүла Казый Мөхсин, Мәүлана Исхак, Бәркә Фәкыйһнең лирик шигырьләре һәм башка күпләрнең әсәрләре дөнья әдәбияты хәзинәсенә керде. Алтын Урда дәверенең гаять зур вакыйгалары «Идегәй» дастанында чагылыш таба. Татар фольклорчысы Нәкый Исәнбәт әлеге эпосның 25 татар, 7 кырымтатар, 3 башкорт, 2 казах, 2 нугай, берәр данә каракалпак, ойрат, төрекмән һәм үзбәк вариантларын табып-барлап, аны 1940–1941 елларда актив фәнни әйләнешкә кертә. Югарыда искә алынган әсәрләр төрки-татар әдәбиятының нигезен хасил итеп һәм бүгенгәчә дәвамчылык юнәлешләрен билгеләп, аның классикасына әверелә.

Матур әдәбият белән бергә, Алтын Урда шәһәрләрендә җирле һәм читтән килгән авторлар тарафыннан риторика, теософия, шәригать, табигыять фәннәре (гамәли һәм теоретик юнәлешләрдә), медицина буенча фәнни трактатлар да иҗат ителә; анда «гарәп йолдызчылары (астрологлары – Б.Х.), мөселман рухани галимнәре, Коръән белгечләре, математиклар һәм астрономнар мәдәнияте» чәчәк ата [Г.А.Федоров-Давыдов]. Биредә аерым игътибарга лаек мисалны китерү урынлы: Николай Коперникның (1473–1543) гелиоцентрик концепциясе барлыкка килгәнче 150 ел элек Сәйф Сараи (1321–1396) үзенең «Сөһәйл вә Гөлдерсен» поэмасында образлы рәвештә Җирнең Кояш тирәли әйләнүе хакында искә ала. Шулай ук безнең көннәргәчә килеп җиткән әсәрләр аша Алтын Урдага нисбәтле сәяхәтнамәләр, сүзлекләр, историографик һәм генеологик (шәҗәрәи) хезмәтләр иҗат ителүе мәгълүм.

*Дәвамы бар*

2001 елның августыннан чыга

# Мәйдан

№6 (235)
**ИЮНЬ /2021**

Гамәлгә куючы:
«Татмедиа» акционерлык җәмгыяте
(420097, Казан, Академиклар урамы, 2)

Баш редактор Рөстәм Госман улы ГАЛИУЛЛИН

РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:

**Әлфия ӘДИЯТОВА** (Казан)
**Фирдүсә ӘЮПОВА** (Чаллы)
**Дилбәр БУЛАТОВА** (Уфа)
**Разил ВӘЛИЕВ** (Казан)
**Фәридә ГАБИДУЛЛИНА** (Алабуга)
**Рафаил ГАЗИЗОВ** (Мамадыш)
**Фоат ГАЛИМУЛЛИН** (Казан)
**Рөстәм ГАНИЕВ** (Түбән Кама)
**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА** (Казан)
**Илдус ЗАҺИДУЛЛИН** (Казан)
**Наил МӘҺДИЕВ** (Чаллы)
**Илдар МИРГАЛИМОВ** (Казан)
**Рүзәл МӨХӘММӘТШИН** (Казан)
**Фоат САДРИЕВ** (Мөслим)
**Ркаил ЗӘЙДУЛЛИН** (Казан)
**Факил САФИН** (Чаллы), редакция советы рәисе
**Равил ФӘЙЗУЛЛИН** (Казан)
**Энгель ФӘТТАХОВ** (Актаныш)
**Рамил ХӘЛИМОВ** (Чаллы)
**Рәфкать ШАҺИЕВ** (Әлмәт)
**Әнвәр ШӘРИПОВ** (Чаллы)
**Рафаэль ЮНЫСОВ** (Чаллы)

РЕДАКЦИЯ КОЛЛЕКТИВЫ:

иҗат төркеме:

**Факил САФИН** (баш редактор урынбасары)
**Лилия ГЫЙБАДУЛЛИНА** (шигърият бүлеге)
**Гөлшат ИЛАЛЕТДИНОВА** (җаваплы секретарь)
**Светлана ФӘИЗОВА** (проза бүлеге)
**Гөлнар КАРАЕВА** (сайт редакторы)
**Сәмәрә ХӘЙРУЛЛИНА** (гомуми бүлек редакторы)

гамәли хезмәткәрләр:

**Резеда ГАТИНА** (баш бухгалтер)
**Индира ВӘЛИЕВА** (компьютерда биткә салу операторы)

Идел буе регионында Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәте идарәсендә ПИ № ФС77-76913 саны белән 2019 елның 1 октябрендә теркәлгән. Журналның индексы – П2356. Редакция һәм нәшрият адресы: 423827, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Яшь ленинчылар бульвары, 9 нчы йорт (27/19), «Мәйдан». Телефоннар: (8552) 59-75-84, 59-65-84.

E-mail: **maydan06@mail.ru**, сайт адресы: **maydan.tatar**

Җыярга тапшырылды: 30.04.21. Басарга кул куелды: 31.05.21. Компьютерда җыелды. Катнаш гарнитура. Офсет ысулы белән басылды. Күләме – 10,0 басма табак.
Форматы: 70х100/16. Тиражы – 1633 данә. Заказ – Е-1723.
Ярты елга язылу бәясе – 507 сум.

Кульъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый. Редакция фикеренә тәңгәл килмәгән язмалар да басыла. Күчереп басканда «Мәйдан»нан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри. Авторларның язмаларында табылган хаталар һәм кимчелекләр өчен редакция җавап бирми.

6+

«Татмедиа» акционерлык җәмгыяте филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. 420066, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2.

© «Мәйдан», 2020.

| | | |
|---|---|---|
| **Татар шигыре** | **3**<br>**4** | Роберт МИҢНУЛЛИН. **Үз илеңдә**<br>**Шундый инде без менә** |
| **Чәчмә әсәр** | **5** | Зимфира ИСЛАМОВА. **Тормыш имтиханы** |
| **Шигъри гөләндәм** | **34** | Айрат СУФИЯНОВ. **Күкләр дәшми** |
| **Чәчмә әсәр** | **38** | Әлфия СИТДЫЙКОВА. **Диңгез суы тозлы ул** |
| **Шигъри гөләндәм** | **71** | Рафига УСМАНОВА. **Сәгать-сәгать газиз гомер үтеп бара** |
| **Тарих** | **75** | Булат ХӘМИДУЛЛИН**. Алтын Урда һәм аның тарихи мирасы** |
| **Чаллы хикәяләре антологиясе** | **86** | Идрис РЫСКУЖИН. **Җәһәннәмнән качу** |
| **Яшьләр иҗаты** | **101** | Алинә ХИСАМИЕВА. **Синле дөньям** |
| **Яңа исемнәр** | **105** | Рәзиф ДӘҮЛӘТ БИКБАУЛЫ. **Эт оясы** |
| **Әдәби мохит** | **120** | Рухия АХУНҖАНОВА. **Туфанның шигъри тылсымы** |
| **Канатлы сүзләр** | **124** | Равил МОСТАФИН |
| **Юбилей** | **125** | Габделхәй САБИТОВ. **Хәвефле җәй** |
| **Тормыш һәм гамь** | **130** | Люзия ХӘБИБУЛЛИНА. **Тамырларда – гыйбрәтле тарих** |
| **Татарстанда Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы** | **133**<br>**136** | Лилия ГЫЙБАДУЛЛИНА. **Чулман ярларында Ак кала**<br>Энҗе ХАРИСОВА. **Бай тарихлы белем йорты** |
| **Шаян сәхифә** | **139** | Марсель ВӘЛИТОВ. **Фәхри бабай һәм ясалма акыл маҗаралары** |
| **Әдәби-иҗтимагый тормыш** | **143** | |
| **«Мәйданчык» кушымтасы** | **145** | Рөстәм ГАЛИУЛЛИН. **Әскәр укырга өйрәнә** |

Тышлыкның 1 нче битендә – Чаллы, М.Вахитов исемендәге 2 нче гимназия.
Факил Сафин шигыре




Булат ХӘМИДУЛЛИН

# Алтын Урда һәм аның тарихи мирасы*

7

Дәүләттә төрле диннәр хөкем сөрү Җүчи Олысының аерылгысыз сыйфаты була. Монгол-татарларның басып алулары чорында алар үзләре башлыча тәңрегә табыналар һәм өлешчә буддачылык динендә булалар, Урта Азиядә һәм Идел-Чулман Болгарстанында – ислам, рус җирләрендә – христианлык хакимлек итә, Кырымда һәм Кавказда христианлык, ислам, яһүдилек тарала. Алтын Урда составына кертелгән күп кенә халыклар (мәсәлән, фин-угор халыклары, кыпчакларның бер өлеше) ул чорда мәҗүсилектә гомер кичерә.

Күп очракта ханнарның буйсындырылган халыкларның диннәренә, мәдәниятенә һәм традицияләренә карата төптән уйланылган һәм салмак сәясәт алып барулары нәтиҗәсендә Җүчиләр дәүләте ике йөз елдан артык яшәп килә. Урта гасырлар, Рим папасы һәм аның даирәсе Көнбатыштагы дәүләтләр идарәчеләре белән берлектә оештырган тәре йөртүчеләр яулары дәверендә гаять зур дәүләт үлчәмендә әлеге сыйфат уникаль күренеш була.

* Ахыры. Башы 4, 5 нче саннарда


294478 251
СБОРНИКЪ
МАТЕРІАЛОВЪ, ОТНОСЯЩИХСЯ КЪ ИСТОРІИ
ЗОЛОТОЙ ОРДЫ.
В. ТИЗЕНГАУЗЕНА.
ТОМЪ I
ИЗВЛЕЧЕНІЯ I

*Тизенгаузен җыентыгы*



*Мәнгү Тимер тәңкәләре. 1269—1282 еллар. Чекан Болгар шәһәре*

Монгол-татарларның диннәргә тигез карашы хокукый яссылыкта беркетелә: Чыңгыз хан «Яса»сы башка халыкларның дини ышануларына карата ихтирамлы мөнәсәбәттә булуны рәсмиләштерә, аларны мыскыллаган өчен үлем җәзасы карала. Чыңгыз хан һәм аның варислары Евразиянең яуланган халыкларын һәм дәүләтләрен буйсындыру формалары хакында төптән уйлап һәм отышлы якларны алдан фаразлап эш итәләр. Әлеге халыкларның диннәре һәм руханилары алар хакимиятен бәреп төшерүгә өндәмәгән очракта монгол-татарлар ул диннәргә карата максималь дәрәҗәдә түземле һәм хәтта химаячел мөнәсәбәттә булалар. «Дөньяны буйсындыручылар» сәяси хакимлеккә ирешүгә әһәмият бирәләр, үзләренең рухи кыйммәтләрен ирексезләп тагу аларның максатына керми. Шуңа күрә, Үзәк Евразиядә үз хакимиятләрен урнаштыру чорында Монгол империясенең Җүчи Олысы идарәчеләре яуланган җирләрдә таралган диннәрдән һәм дини ышанулардан, битарафлык күрсәтеп, ераклашалар, ягъни ул тәртипләргә тыкшынмыйлар.

Монгол империясенең көнбатышында Бәркә хан (идарә итү еллары: 1257–1266) заманында, Бату вафатыннан соң хан тәхете өчен көрәш җәелгән шартларда дини вазгыять үзгәрә. Хан тәхетенә бер яктан – Монгол империясе эчендә бердәмлекне саклау тарафдарлары – Батуның христиан динендәге хатыны Баракчин һәм аларның улы Сартак, икенче яктан ислам кабул иткән һәм Җүчи Олысын бөек каганга буйсынудан арындыру омтылышында мөселман сәүдәгәрләре тарафыннан яклау һәм хуплау тапкан Бәркә дәгъва кыла. Шулай итеп, ислам Җүчиләрнең сәяси аерымлануының бер факторына әверелә.

Хакимият өчен барган көрәштә Бәркә җиңүгә ирешкәч, Алтын Урдада исламның позицияләре шактый көчәя. Ханның хатыннары, күп кенә югары түрәләр, хәрби җитәкчеләрнең бер өлеше ислам кабул итә. Бәркә чорында ислам дәүләт дине үк булып җитмәсә дә, ул аксөякләр даирәсендә генә түгел, гади күчмәннәр арасында да тарала башлый; хәер, бу күренеш ул чакта массачыл колач алмый әле. Бәркә хан идарә иткән елларда ислам традицияләре акрынлап дәүләт идарәсе системасына тартыла, мөселман



*Браслет. Җүси Олысы XIV гасыр. Дәүләт эрмитажы*



*Олуг Мөхәммәтнең Төрек Солтанына хаты*

мораль-әхлакый кыйммәтләре Алтын Урда җәмгыятенең көндәлек тормышына үтеп керә.

Шул чордан башлап Җүчи Олысының тышкы сәясәте формалашканда – союздашларны һәм дошманнарны, йогынты төбәкләрен тәгаенләгәндә һәм башка мәсьәләләрдә ислам мөһим факторларның берсенә әверелә. Аерым алганда, Иран илханы, христианнарны үз күргән ике туган кардәше Һулагу (аның өлкән хатыны несториан юнәлешендәге христиан динендә була) белән Кавказ арты өчен көрәш алып барганда, мөселман илләре йөзендә союздашлар җәлеп итү өчен Бәркә дини факторны файдалана. Бу исә Җүчи Олысының православиеле Византиягә, Көнбатышның католик динендәге илләренә, аларның Якын Көнчыгыштагы тәре йөртүчеләре биләмәләренә карата дошманлык һәм сәлҗук төрекләре һәм Мисыр мәмлүкләре белән союздашлык мөнәсәбәтләре вазгыятенә бәйләнә.

Алтын Урданың шуннан соңгы идарәчеләре – Мәнгү Тимер (1269–1282), Туда Мәнгү (1282–1287), Тула Буга (1287–1291) һәм Тукта (1291–1312) ханнар заманнарында Җүчи Олысының дәүләт эчендәге һәм тышкы сәясәттәге гамәлләрендә ислам роленең көчәя бару тенденциясе саклана. Шулай итеп, XIV гасыр башына аяк басканда Алтын Урдада исламны дәүләт дине сыйфатында кабул итү өчен шартлар өлгереп җитә, Үзбәк хан идарә иткән елларда (1313–1341) ул гамәлгә ашырыла (Симеон елъязмасында күрсәтелгәнчә, хан, «бәсәрмәнләшеп», Мөхәммәд исемен ала). Нәтиҗәдә Җүчи Олысы ислам цивилизациясенең бер өлешенә әверелә, аның өчен әлеге цивилизациянең матди һәм рухи казанышларына юл ачыла. Үзбәк (аның җәйге станы 1320 елга кадәр Наручат шәһәрендә урнаша) һәм улы Җанибәк (1342–1357) чорында күпсанлы мөселман тәшкиләтләре – мәчетләр, мәдрәсәләр, мәктәпләр, ханәкәләр, тәкияләр, дөрбәләр, зәвияләр һәм башкалар бина-лана. Сарай әл-Җәдидтә – Харәзем осталары, Кырым/Солхат шәһәрендә Мисыр мигъмарчылары тарафыннан

мәчетләр төзелү мөселман дөньясы белән багланышларның киңәюен чагылдыра.

Шул ук вакытта исламның позицияләре ныгуы һәм аның дәүләт дине дәрәҗәсенә күтәрелүе Алтын Урдада динара низаглар уятмый. Аның каравы, 1261 елда Бәркә хан заманында Сарайда митрополит Кирилл тарафыннан православие епархиясе оештырыла; 1315 елда, Үзбәк хан чорында шунда ук францисканнар миссиясе нигезләнә, 1336 елга Алтын Урда территориясендә шундый оешмаларның саны унга җитә.

Алтын Урда цивилизациясендә диннәргә тигез карау элементларының саклануында Бохара һәм Харәзем дин әһелләре һәм вәгазьчеләре алып килгән хәнәфиләр мәзһәбенең (сөнничелек исламында дүрт хокукый мәктәпнең берсе) һәм, һичшиксез, динара хезмәттәшлекнең ханнарга китергән икътисади һәм сәяси файдасының да өлеше бар. Күпкә соңрак, Мәскәү белән үзара каршы тору башлангач кына, әлеге көрәштә катнашучыларның дини асылы хакындагы мәсьәлә алга чыга.

Исламның Алтын Урданың дәүләт дине сыйфатында кабул ителүе дәүләт территориясендә барган этномәдәни һәм этносәяси процесслар белән тыгыз бәйләнгән. Шәһәрләшү белән бергә, ул төрки (болгар, угыз, кыпчак һәм башка) һәм бик аз дәрәҗәдә монгол элементлары җирлегендә бердәм татар этносы формалашуның гаять мөһим системалаштыру факторына әверелә.

Үзбәк һәм Җанибәк ханнарның идарә итү чорларын Алтын Урданың иң куәтле заманы буларак күзаллау да турыдан-туры исламның Җүчи Олысының рәсми диненә әверелүенә барып тоташа. Әлеге караш, кайчандыр булып узган колачлы яулаулардан бигрәк, дәүләтнең эчке төзелешенең сәүдә-игенчелек төбәкләренең (Идел-Чулман Болгарстанының, Кырымның, Харәземнең һәм башка өлкәләрнең) җирле дәүләти төзелеш традицияләре нигезендә мөселман кануннарына яраштырып камилләштерелүе белән бәйле.

Үзбәк-Мөхәммәд илдә үзгәртеп корулар, әүвәл нәүбәттә мәхкәмә һәм хакимият реформалары уздыра. Беренчесе кысаларында мөселман мәхкәмәләре – казыятлар гамәлгә кертелә, аларда гадел хөкем, карарлар шәригать нигезендә чыгарыла. Шунысы игътибарга лаек, алар берьюлы гына кертелми, шул ук вакытта элеккечә үк төрки-монгол мәхкәмәләре – яргулар да гамәлдә кала. Дәгъвачылар аларның кайсына мөрәҗәгать итәргә икәнен сайлый алалар, бу хакта гарәп сәяхәтчесе, «Төхфәтен-наззар фи гаранбел-әмсар вә гаҗәибел-әсфар» («Төрле шәһәрләр һәм сәфәрләрдә гаҗәеп хәлләргә шаһит булучыларга бүләк») китабы авторы Ибне Баттута хәбәр итә.

Үзәкләштерүче башлангычларны ныгыту аша илнең гаять зур территориясен идарә итүнең нәтиҗәлелеген күтәрүгә зур әһәмият бирелә. Моңа бәйле рәвештә Җүчинең күпсанлы варислары биләмәләре – 70 төмәнгә, соңгылары үз чиратында 10 эре олыска берләштерелә, һәр олыс башына хан тарафыннан олыс бәге билгеләнә. Шулай ук үзәк хакимиятне ныгыту максатында җирле феодалларның хокуклары кыскартыла – хәзер инде алар үз гаскәрләрен туплый һәм халыктан салымнар җыя алмыйлар, бу

эшләр хан түрәләренә тапшырыла. Моңа алмашка аксөякләргә хан казнасыннан билгеләнгән түләүләр бирелә, ләкин ул түләүләр берничек тә аларның югалтылган икътисади һәм өлешчә сәяси мөстәкыйльлеген тулаем каплый алмыйлар; бу исә аларның ризасызлыгына сәбәпче була.

Үзбәк бик актив тышкы сәясәт алып бара, әмма әлеге сәясәтнең барлык юнәлешләре дә уңышлы булмый. Үзбәк Һулагу варислары белән Әзербайҗан өчен уңышсыз сугышларга тартыла, Балкан ярымутравында Җүчи Олысы контролен торгызуга ирешми, көчәя барган Литва бөек кенәзлеге белән үзара каршы торуда Урда көньяк-көнбатыш җирләрдә контролен югалта. Тышкы сәяси мәйданда Үзбәк хан казанышларының берсе – бәхәссез, аңарчы яңарак кына Тукта хан тарафыннан Кырымнан куып чыгарылган Венеция сәүдәгәрләре белән үзара файдалы мөнәсәбәтләрнең торгызылуы. Үзбәк аларга Кара диңгез буенда үз факторияләрен төзергә рөхсәт бирә, әлеге факторияләр венециялеләргә зур табыш китерә, Кара диңгездәге сәүдә өчен алынган салымнар Урда казнасына керә.

Үзбәк хан идарә иткән елларда вассал рус кенәзлекләре белән үзара мөнәсәбәтләрдә яңа тенденцияләр чалымлана. Алар, Үзбәккә кадәр Тукта хан алып барган сәясәттән, ягъни Җүчи Олысы ханына карата карусыз лояльлек шартларында рус җирләренең эчке эшләренә тыкшынмау сәясәтеннән аермалы хәлдә, рус кенәзлекләре эшләренә актив тыкшынудан гыйбарәт була. Әмма, замандашыбыз Роман Почекаев фикеренчә, «... аның (Үзбәкнең – *Б.Х.*) Русьтагы сәясәте Алтын Урда өчен бик үк уңай булмаган нәтиҗәләргә китерә. Руслар эшләренә тыкшынып, ул кенәз нәселләренең берсе – Мәскәү кенәзләренең көчәюенә булышлык итә. Мәскәү кенәзләре исә (Иван Калита һәм аның варислары) бик тә энергияле һәм дәгъвачыл идарәчеләр булып чыга, алар кыска гына вакыт эчендә барлык Төньяк-Көнчыгыш Русь өстеннән контроль урнаштыруга ирешәләр...»

Чыннан да, теләпме яисә теләмичәме, ул заманда Мәскәү кенәзлегенең тиз арада көчәя һәм аның территориясе киңәя башлавы өчен Үзбәк хан кулай, максималь дәрәҗәдә мөмкин булган барлык шартларны тудыра. Башкача әйткәндә, Үзбәк идарә иткән елларда Мәскәүнең ныклы икътисади «мускуллары» барлыкка килә, киләчәктә Мәскәүнең ачыктан-ачык Алтын Урдага каршы торуы өчен нигез формалаша, бу хакта, аерым алганда, Мәскәү тарихчысы Антон Горский билгеләп уза. Ул заманда Иван Калитаның һәм башка рус кенәзләренең Җүчи Олысы контроленнән чыгуны ниятләп, еракка төбәлгән планнар коруы шикле, өстәвенә татар ханнары «канаты» астына сыенып идарә итү алар өчен кулай һәм уңайлы була; әмма, һичшиксез, Мәскәүнең көчәюендә әлеге тарихи чор һәм Үзбәк ханның шәхси хәерхаһлыгы үтә мөһим роль уйный.

Гомумән алганда, Үзбәкнең рус елъязмаларында «мәрхәмәтле» дип аталган улы Җанибәк хан (идарә итү еллары: 1342–1357) атасының сәясәтен дәвам итә. Ул, Мәскәү кенәзләренә ярдәм күрсәтеп, шул ук вакытта башка рус кенәзлекләре белән үзара мөнәсәбәтләрдә аларга артык зур вәкаләтләр бирмичә, Мәскәүнең үсә барган куәтенә каршы торырлык

чаралар системасын саклап килә. Кайчандыр бердәм булган Иран илханнары (Чыңгызыйлар – Һулагу варислары) дәүләтенең бер-берсе белән сугыш хәлендәге мөстәкыйль биләмәләргә таркалуыннан файдаланып, Җанибәк Әзербайҗанны үз дәүләтенә кушуга ирешә. Кара диңгез буйларындагы итальян колонияләренә каршы тору аның идарәсе чорының аерым сәхифәсен тәшкил итә – низаг әлеге хан идарәсенең ахырынача диярлек сузыла.

Җанибәк хан вафат булып, аның улы Бирдебәк кыска гына вакыт (1357–1359) тәхеттә утырганнан соң, Җүчи Олысында рус елъязмаларында «Олуг болганыш» («Великая замятня») буларак искә алынган чор башлана. Бирдебәк вафатыннан соң, атасының тәхетенә хуҗа булу өчен исән чагында аның тарафыннан иң якын кондәш туганнары кырылып бетү сәбәпле, аның турыдан-туры варисы калмый. Ләкин аксөякләр арасында Җүчиләр белән төрле дәрәҗәдә кардәш затлар була, бу исә төрле сәяси кланнар өчен аларны хаклы дәгъвачылар сыйфатында тәхеткә чыгаруга нигез тудыра. Нәтиҗәдә 1359–1380 елларда, кинаяләп әйткәндә, ханнар бер-бер артлы күз иярмәслек тизлек белән алмашына (аларның кайберләре хакында берни дә мәгълүм түгел), шундый вазгыять хөкем сөргән шартларда күп кенә олыслар бәйсезлеккә омтылалар. Сарай даирәсендәге көрәш чын мәгънәсендә гражданнар сугышына әверелә.

Алтын Урданың элеккеге бөеклеген кайтару юнәлешендә бик актив сәясәт алып барган Туктамыш хан (1380–1395) беркадәр вакытта дәүләтнең таркалуын туктатып тора. Дошманы Мамайның рус гаскәрләре тарафыннан тар-мар ителүеннән файдаланып һәм көч җыйган Урта Азия идарәчесе Аксак Тимер булышлыгы белән (бу ярдәм вакытлыча булып чыга) Туктамыш илне берләштерүгә ирешә. Ләкин тиздән элеккеге союздашлар Туктамыш һәм Аксак Тимер арасында Әзербайҗандагы һәм Ирандагы территорияләр мәсьәләсе аркасында низаг чыга. Җитмәсә, Туктамыш гаскәрләре Урта Азия шәһәрләренә һөҗүм ясыйлар. Болар барысы да ике идарәче арасында күпьеллык хәрби хәрәкәтләр җәелүгә китерә, алар барышында, 1390 елларның беренче яртысында, Аксак Тимер Алтын Урда татарларын берничә тапкыр тар-мар итә, шуннан соң инде Алтын Урда ныгытып аякка баса алмый [*И.М. Миргалиев хезмәтләрен кара*].

Үзәк хакимиятнең көчсезләнүе шартларында икътисади җәһәттә ныграк үсеш алган, социаль-сәяси тетрәнүләрдән азрак зыян күргән һәм шул ук вакытта монголларгача дәвердә дәүләтчелек тәҗрибәсе булган өлкәләрдә актив рәвештә сәяси аерымлану омтылышлары башлана. Тәүге нәүбәттә бу күренеш Урта Идел буе (Болгар олысы һәм үзәге Наручаттагы Мухша олысы), Кырым һәм Урта Азия (Харәзем) кебек территорияләргә хас була.

**8**

Инде билгеләп үтелгәнчә, XIV гасырның беренче яртысында, бигрәк тә Үзбәк (1313–1341) һәм Җанибәк (1342–1357) ханнар идарә иткән заманда Алтын Урда чәчәк ату чоры кичереп, үзенең иң югары куәтенә ирешә. Әмма шул ук гасырның икенче яртысында Җүчи Олысы бер үк ва-

кытта төрле авыр сынауларга дучар була.

Җүчи Олысын кисәк кенә көчсезләнүгә һәм шуннан соң таркалуга китергән сәбәпләр төрле, шуңа күрә Алтын Урдада XIV гасырның икенче яртысында барган процессларны фәкать дәүләтнең сәяси тормышындагы вакыйгаларга кайтарып – үзәктән читләшү тенденцияләре һәм татар аксөякләренең хан тәхете өчен барган көрәше белән генә аңлату һич тә дөрес түгел. Һичшиксез, әлеге фактор Җүчиләр дәүләтенең көчсезләнүендә мөһим роль уйный, әмма бердәнбер һәм төп сәбәп булмый.

Иң элек климаттагы планетар колачлы үзгәрешләр белән бәйле коточкыч экологик афәткә тукталып узыйм. Глобаль салкынаю (Кече бозлык дәвере дип аталган чор башлану) XIV–XV гасырларда Евразия далаларының көнбатыш өлешендә корылыкка, явым-төшемнәрнең кимүенә, кышларның аз карлы булуына, кайчандыр мул яшеллекле көтүлекләрнең комлануына китерә. Бер үк вакытта, Каспий диңгезенең суы күтәрелүе нәтиҗәсендә, Идел дельтасының зур өлеше һәм шунда урнашкан күп кенә торулыклар су астында кала, тозлы су Түбән Идел буендагы шәһәрләрне кысрыклый. Болар барысы да терлекчелек һәм игенчелек мәйданнарына гаять зур зыян сала, Җүчи Олысы халык хуҗалыгының җимерелүгә йөз тотуына сәбәпче була. Аңарчы дистәләрчә еллар дәвам иткән тотрыклы һәм мул тормыш (белгәнебезчә, Кече бозлык дәверенә кадәр Кече климатик оптимум – чагыштырмача җылы һәм салмак һава торышлы, җылы кышлы һәм көчле корылыклар булмаган чор хөкем сөргән) демографик үсешкә һәм халыкның илнең көньяк төбәкләренә күченүенә, нәтиҗәдә, кайбер галимнәр фикеренчә, бу хәл халык урнашуның артык тыгызлануына китерә. Соңыннан исә, табигать-климат уңайлыклары начарайган шартларда, халыкның чиктән тыш туплануы сәбәпле, шул төбәкләрдә азык-төлек кризислары ешаеп һәм алар ара-тирә коточкыч ачлык тудырып, кешеләр котылу эзләп, яшәгән урыннарыннан кубарылып башка җирләргә китәргә мәҗбүр булалар.

Бер үк вакытта диярлек Евразиягә «кара үлем» – дәһшәтле бубон чумасы пандемиясе ябырыла. XIV гасыр уртасында һәм икенче яртысында, бигрәк тә халык аеруча тыгыз урнашкан өлкәләрдә һәм, тагын да аянычрагы, административ, икътисади һәм мәдәни җәһәттә үзара бәйләүче үзәкләр булган шәһәрләрдә халыкны кырып, ул Дәште Кыпчак аша берничә тапкыр уза. Җүчи Олысында бу афәт фаҗигале нәтиҗәләргә китерә. Замандашлар анда чума эпидемиясеннән «авыллар һәм шәһәрләр кешесез (бушап –*Б.Х.*) калдылар» дип язалар. Урта гасырларда яшәгән авторлар хәбәрләренә караганда, Кырымда көн саен меңләп кеше үлә. Илнең нинди зур югалтулар кичерүен күз алдына китерергә мөмкин. Нәкъ менә шул вакыттан Идел буенда шәһәрләрдәге тормыш сүрелә башлый.

Җүчи Олысының бетүгә йөз тотуында Евразия сәүдәсе кризисының да өлеше бар. Кытайдан башлангыч алып, өлешчә Алтын Урда аша узган атаклы Ефәк юлы буйлап товар алмашуның кимүе XIV гасырның 40 нчы елларында ук башланып, аның икенче яртысында иң түбән ноктага тәгәри. Аның сәбәпләре арасында –

Кытайда Юань династиясенә каршы азатлык хәрәкәте, Урта Азиядә һәм Монголстанда тотрыксыз вазгыять, Кече Азиядә чума эпидемиясе һәм Илханнар дәүләте таркалганнан соң туган низаглар, Урта диңгез буендагы төп сәүдә державалары Генуя һәм Венеция арасында барган сугыш. Алтын Урда шәһәрләренең һәм дәүләтнең барлык икътисади системасының хәлен кискенләштереп, болар барысы да Шәрыкъ һәм Гареб арасындагы товар әйләнешенең чикләнүенә китерә.

Һичшиксез, 1360 еллардан башлап өзлексез дәвам иткән социаль-сәяси кризиста чагылган эчке сәяси процессларны да исәптән сызарга ярамый. Әлеге кризис, хан тәхете өчен барган тукталмас көрәш («Олуг болганыш» чорында (1359–1379) Урда тәхетендә 20 дән артык хан алмашына) буларак башланып, XV гасырга аяк басканда үзәктән читләшә-аерымлана бару һәм сепаратчылык тенденцияләренең көчәюе рәвешенә керә, бу хакта 1960 елда ук Мөхәммәд Сәфәргалиев үзенең мәгълүм «Алтын Урданың таркалуы» монографиясендә тәфсилле бәян иткән иде.

Экологик бәлаләр, чума эпидемиясе, икътисади кризис, эчке сәяси низаглар нәтиҗәсендә хәлсезләнгән Алтын Урдага Сәмәрканд әмире, Тимериләр империясен нигезләгән Аксак Тимер җимергеч һөҗүм ясый. Аның гаскәрләренең 1391 һәм 1395 еллардагы яулары Алтын Урданың аеруча алга киткән һәм мөһим төбәкләрен – Төньяк Кавказны, Кубань, Днепрның сул як ярының түбәнге өлеше, Кырым, Донның урта агымы өлкәләрен, Түбән һәм Урта Идел буйларын колачлый, әлеге төбәкләрдә урнашкан барлык мөһим шәһәрләр, шул исәптән Үкәк, Билҗәмин, Гөлстан, Сарай, Хаҗитархан, Маҗар, Азак, Кырым/Солхат һәм башкалар хәрабәләр хәленә китерелә. Дәүләтнең күп кенә шәһәр үзәкләренең җимертелүе сәүдәнең һәм, гомумән, икътисадның тәмам бетүгә йөз тотуына китерә, чынлыкта административ система юкка чыгарыла һәм, ахыр чиктә, Җүчи Олысының язмышы хәл ителә.

Ябырылган барлык сынаулар өермәсен Алтын Урда күтәрә алмый һәм шуннан соң инде аякка басмый. XV гасыр башында Җүчи Олысында тотрыклылыкны кайтару максатында әмир Идегәй (яшәгән еллары: 1352–1419) тарафыннан гамәлгә ашырылган реформалар (үзәкләштерүне ныгыту, акча реформасы, исламның актив рәвештә яңа таралышы) һәм ирешелгән хәрби тышкы сәяси уңышлар нәтиҗәсендә, асылда бөек империянең һәлакәте кичектерелеп, аның үлем газабы озая гына. Сәяси, социаль, икътисади һәм табигый-климатик сәбәпләр аркасында XV гасырның икенче утызъеллыгында Җүчи Олысы бердәм дәүләт сыйфатында яшәүдән туктый.

Әмма Алтын Урданың таркалуы аның традицияләре дәвамчылары, урта гасырларда хөкем сөргән бөтенлекле конфедерация хасил иткән дәүләтләр «йолдызлыгы» оешуга китерә. Алтын Урда олыслары җирлегендә яңа дәүләт-«йорт»лар – Җүчиләрнең Олуг Олыс (Олы Урда, 1441–1502), Кырым (1441–1783), Казан (1445–1556), Касыйм (1445–1681), Төмән/Себер (1446–1598), Әстерхан (1459-1556), Үзбәк (1469–1510) һәм Казах (1469–1718) ханлыклары, Идегәй варисларының Нугай Урдасы (1480–1613), шулай ук Үзәк Европадан Үзәк

Азия һәм Себергә кадәрге территориядә төрле дәрәҗәдә Алтын Урда сәяси системасының, икътисадының һәм мәдәниятенең традицияләрен мирас иткән кечерәк дәүләти берләшмәләр барлыкка килә.

Глобаль тарихи үлчәмнәрдән чыгып фикер йөрткәндә, кыска вакытлы яшәвенә карамастан, Алтын Урда тирән тарихи эз калдыра. Аның гаять зур территориясе, хәрби куәте, киң колачлы халыкара йогынтысы, көчле дәүләт аппараты, югары үсешкә ирешкән күп укладлы икътисады, бай мәдәнияте булган; ул Евразиянең сәяси, икътисади һәм этномәдәни картасына тирән һәм әтрафлы юнәлешле йогынты ясаган. Болар барысы да тулы ышаныч белән аңа карата урта гасырларның бөек өстен державасы эпитетын куллануга мөмкинлек бирә. Үзенчәлекле сәяси, хуҗалык, мәдәни, социаль институтлары бердәм комплексының югары дәрәҗәдәге үсеше, вакыт һәм пространство җәһәтендә локальләшкән һәм тотрыклы, бөтенлекле иҗтимагый система буларак, үзенә бер төрле «Алтын Урда цивилизациясе» турында сүз йөртергә җирлек тудыра. Җүчи Олысы составына кергәндә төрле халыклар үсешнең төрле баскычларын билиләр: бер ишләре күпгасырлык дәүләтчелеккә, хезмәт бүленешенә һәм сыйнфый җәмгыятькә ия була, икенчеләре ыруг-кабилә мөнәсәбәтләрендә яшәп, натураль хуҗалык алып бара; өченчеләре югары мәдәнияткә ирешә; кем өчендер исә хәтта язу да ят була. Шуңа күрә, яулау һәм көч куллану юлы белән барлыкка килсә дә, киләчәктә Алтын Урда, һичшиксез, гаять зур берләштерүче һәм мәгърифәтчел роль уйный.

Яшәүдән туктаса да, Алтын Урда эзсез югалмый. Аның ифрат зур мирасы кала. Элегрәк язганымча, әлеге мирас – Алтын Урданың «этник бишеге»ндә яралган, «татар» атамасын горур йөрткән ике милләт һәм башка халыклар, исламның зур киңлекләрдә җәелүе, хәзерге татар теле һәм башка төрки халыкларның әдәби телләре формалашуы өчен нигез булган гомумтөрки әдәби тел, дәүләтчелек үсешенең яңа баскычы һәм башкалар. Моннан тыш, нәкъ менә Алтын Урда соңыннан Россия составына кергән төрки, монгол, фин-угор, көнчыгыш славян, Себер, Кавказ һәм Евразиянең башка халыкларына тәүге үзара социаль-сәяси, этномәдәни якынаю, тәэсир итешү һәм баетылу тәҗрибәсе биреп, тормыш рәвеше һәм менталитет охшашлыгы яралгысын хасил итеп, аларны бөтенлекле бергәлеккә туплый. Алтын Урда «канаты» астында барлыкка килеп һәм ныгып, Мәскәү Русе тиздән аңардан Евразия җирләрен җыю эстафетасын үзенә ала. Алтын Урда белән бергә яшәү дәверендә калган тәҗрибә (уңае да, тискәресе дә) вакытлар узу белән Русь – Россиягә дөньяның иң зур дәүләтенә әверелү мөмкинлеге бирә.

XIV–XV гасырларда Мәскәү Русе Җүчи Олысы идарәче катлавының зур өлешен үзенә җәлеп итә, туплый, XVI гасыр ахырыннан (Казан, Әстерхан һәм Себер ханлыклары яулаганнан соң) чынлыкта күпсанлы мөселман халыклары яшәгән, Алтын Урданың күп кенә традицияләрен мирас итеп алган полиэтник ил булып җитлегә. Мәскәү бөек кенәзлеге мисалында һәм Русь–Россия тарихының шуннан соңгы этапларында Алтын Урда мирасының эзләре хәр-

би оештырылуда, акча-фискаль системасында, сарай даирәсе һәм дипломатия эш йөртү протоколында, дәүләт канцеляриясе эшчәнлегендә, аксөякләр титулларында, гомумән, дәүләт төзелеше һәм идарәсе гамәлиятендә, аерым алганда, дәүләт идарәсен үзәкләштерүнең аеруча мөһим принцибында ачык күренә [*мәсәлән, С.С.Аверкиев һәм И.К.Камалов хезмәтләрен кара*]. Россиянең төрки чыгышлы күп кенә кенәз һәм бояр нәселләре формалашуының тамырлары нәкъ менә Алтын Урда һәм Урдадан соңгы ханлыклар заманнарына барып тоташа [*П.Н.Петров, Н.А.Баскаков, А.Х.Халиков, В.В.Трепавлов, И.В.Зайцев, Б.Р.Рәхимҗанов, Д.А.Котляров һ.б. хезмәтләрен кара*]. Чыңгызыйлар нәселеннән һәм урдалы башка татар аксөяк нәселләре варислары булу Россиядә шулкадәр абруйлы саналган ки, кайбер очракларда бояр нәселләре вәкилләре хәтта ясалма рәвештә үзләренең чыгышларын Алтын Урда аксөяк татар тамырларына нисбәт иткәннәр.

Хәзерге вакытта Алтын Урданың Россия дәүләтчелеге формалашуына турыдан-туры яисә читләтелгән хәлдә ифрат зур йогынты ясавы мәсьәләсендә бәхәс куертучылар азайды. Мәскәү кенәзлегенең – Мәскәү патшалыгына, соңгысының Россия империясенә әверелүе Җүчи Олысы таркалып, нәкъ менә аның сәяси һәм территориаль мирасына ия булу өчен көрәш барышында гамәлгә ашырыла. Башта элеккеге Алтын Урда мәйданында гегемон ролен Олы Урда дәгъва кыла, аннан соң дәгъвачы төп көндәшләр булып Мәскәү бөек кенәзлеге һәм Кырым ханлыгы кала.

Әлеге көндәшлектә ни өчен Мәскәү Русе җиңеп чыга соң? Алтын Урда составында Русь, берничә кенәзлек җыелмасы рәвешендә һәм аның эчке автономиясе, традицион сәяси системасы сакланган хәлдә, протекторат статусында була. XIV–XV гасырларда бөек кенәзлек хокукы ярлыгы ханнар тарафыннан башлыча Мәскәү кенәзе Даниил Александрович варисларына бирелә. Бу исә Рюриковичларга (тәүге нәүбәттә Мәскәүдәге Даниловичларга; Юрий Даниловичның Үзбәк хан сеңлесе Кончакка өйләнеп, Чыңгызыйлар кияве титулына ия булуын да онытмыйк), үзәк хан хакимияте ярдәменә таянып һәм Алтын Урданың «рус олысы» куенында ныгый барып, эчке сәясәтне үз мәнфәгатьләрендә алып бару мөмкинлеге бирә. Бөек рус тарихчысы Николай Карамзинның безгә килеп җиткән атаклы «Мәскәү үз бөеклеге белән ханнарга бурычлы» гыйбарәсе буш урында тумаган. Ханнарның Җүчи Олысының үзәк өлкәләрен бөлдергән үзара низаглары Руська әлләни кагылмый; киресенчә, Урдада «Олуг болганыш» чорында дәүләтнең төньяк-көнбатыш чикләрендә хакимият һәм хәрби көч Мәскәү кенәзләре кулында туплана бара, бу исә 1380 елгы вакыйгада – 1370 нче еллар ахырыннан Алтын Урданың законлы идарәчесе Туктамыш ханга каршы торган әмир Мамай гаскәрләренең Мәскәү бөек кенәзе Дмитрий Иванович көчләре тарафыннан тар-мар ителүендә ачык чагыла. Алтын Урданың үзәк төбәкләре икътисадына караганда рус кенәзлекләренең хуҗалыгы Бөек ефәк юлына нисбәтле тышкы сәүдә шартларыннан азрак бәйле була. Сәмәрканд идарәчесе Аксак Тимернең җиңүле яулары да рус кенәзлекләре

территориясен читләтеп уза. Нәтиҗәдә берничә рус кенәзлеге җыелмасыннан гыйбарәт Русь Җүчи Олысы таркалган чорга тупланганрак һәм тотрыклырак хәлдә, шуңа күрә «перспективалырак» дәүләти бергәлек сыйфатында аяк баса. Моның шаһитләре булган күп кенә урдалы татар феодаллары (шул исәптән, кайбер Чыңгызыйлар) рус хезмәтенә күчәләр, рус аксөякләре сафларын тулыландыралар, әлеге күренеш шулай ук русларның (әүвәл нәүбәттә Мәскәүнең) Алтын Урда мирасына дәгъвалары көчәюгә китерә.

Алтын Урданың идарә системасы ике гасырдан артык дәвер дәвамында рус җирләренә зур йогынты ясый. Аның компоненты Русь-Россиянең дәүләт төзелеше һәм идарәсе, финанс системасы һәм ям хезмәте фагыйльлиятендә, аксөякләр титулларында һәм социаль терминологиядә, шулай ук башка өлкәләрдә ачык тоемлана. Мәскәү дәүләтендә «Алтын Урда мирасын саклау стимулы Россиягә кушылган элеккеге Урда халкын татар административ ысуллары ярдәмендә идарә итү зарурлыгыннан гыйбарәт була» [*В.В. Трепавлов*], аерым алганда, салымнар йөкләүнең сакланып калган ясак системасы шуны күрсәтә. Алтын Урда хәзерге вакытта Россиядә һәм аңа күрше территориядә яшәгән халыкларның – татарларның, башкортлар, нугайлар, карачайлар, балкарлар, үзбәкләр, казахларның, шулай ук казакларның һәм башкаларның мөһим өлешен тәшкил иткән күп кенә этносларның һәм этник төркемнәрнең «этник бишеге» була. (Казакларның татар тамырлары хакында XX гасыр башында нәселдән килгән Дон казагы Андрей Гордеев үзенең 4 томлы «Казаклар тарихы» («История казаков») китабында тәфсилле бәян итә, хезмәтнең беренче кисәге «Алтын Урда һәм казакларның яралышы» («Золотая Орда и зарождение казачества») дип атала; яңарак кына Казанда дөнья күргән «Казаклар – төркиләр һәм славяннар дөньяларында» («Казачество в тюркском и славянском мирах») коллектив монографиясендә дә әлеге темага нисбәтле бай һәм кызыклы мәгълүматлар урын алган.)

Шулай булгач, Җүчи Олысыннан (Алтын Урдадан) Җүчиләр ханлыкларының гына түгел (аларның соңгысы – Хива ханлыгы – дөньяның картасыннан XX гасырда гына төшеп кала), Евразиянең бөек державалары – эзлекле рәвештә бер-берсенә гомуми чикләр эчендә «халыкларны җыю» миссиясен тапшыра килгән Россия империясе, СССР, бүгенге Россия Федерациясенең дә дәвамчылык кабул итүләре хакында һич тә икеләнмичә сүз йөртә һәм хәтта шуны раслый алабыз. Нәкъ менә шуның өчен Җүчи Олысы хәзерге Россиянең төрки халыклары үткәненең бер өлеше генә булып калмыйча, бөтен ил тарихының аерылгысыз өлешен тәшкил итә...